C. The word /yartï/ "half" precedes a numeral: ярты йөз "half a hundred".

## 5.3. Pronominal Phrases

There occurs only one type and this is a phrase consisting of a personal pronoun and a substantive in apposition.

1°. With the reflexive noun /üz/ "self" in apposition, the latter always provided with a possessive suffix of the same person as the preceding pronoun: мин үзем "I myself"; син үзең "thou thyself"; алар үзләре "they themselves".

2°. With the noun /hämmä/ "all" provided with a possessive suffix of the same person as the preceding pronoun: сез һәммәгез дә килергә тырышыгыз "you all of yourselves make an effort to come!"

3°. With a collective noun (4.121.2°) in apposition: без дүртәү барабыз "we four [persons] together go".

## 5.4. Adverbial Phrases

Any noun or equivalent phrase provided with a pure-relational suffix or with a pure-relational suffix + postposition, or any noun without pure-relational suffix but with a postposition may occur in adverbial function: ул урманнан килде "he came from the forest"; директор белән сөйләшү "to converse with the director"; дулкынга каршы "against the waves".

In particular, the following types occur:

### 5.41. Attribute + head

The attribute may be:

1°. An adverb: /bik yaxšï/ "very well": бик яхшы укый "he reads very well"; бигрәк тиз "very fast": балык бигрәк тиз үрчи "fish procreates very fast".

2°. An adjective: /akïllï kešečä/ "in the manner of an intelligent person"; /ač büredäy/ "like a hungry wolf".

3°. A noun in the basic form used adverbially: /artïk küp/ "too much" (lit.: "excess much"): артык күп сөйли "he talks too much".

5.42. Head + attribute

In poetry there occur adverbial phrases of the type /karšï utka/ "opposite the fire": өч-дүрт бүре утырганнар каршы утка "three or four wolves sat opposite the fire".

### 5.5. Postpositional Phrases

1°. A noun or a personal pronoun or equivalent phrase followed by a postposition: трактор белән "with the tractor"; китап өчен "for the book"; синең белән "with thee"; авылга таба "in the direction of the village"; кичәдән бирле "since yesterday".

2°. Quasi-postpositional phrases with a noun or equivalent phrase followed by a noun provided with the possessive suffix of the third person: өстәл өстендә "on the table" (lit.: "table on its top").

3°. Personal pronoun + quasi-postposition provided with a possessive suffix corresponding, in person, to the pronoun: минем янымда "by my side".

### 5.6. Verbal Complement

5.61. Equational complement consists of a substantive, pronoun, adjective, or equivalent phrase in the basic (i.e., subject) form with or without a predicative element, i.e., an auxiliary verb or predicative suffix. The predicative element agrees, in person, with the subject. However, agreement in the third person plural is optional.

1°. With a verb: мин студент идем "I was a student"; Мансур исемлектә беренче иде"Mansur was the first in the list"; Латыйпы бик көчле иде "Latïypï was very strong".

2°. With a predicative suffix: ул язучыдыр or ул язучы "he is a writer"; алар студентлардыр "they are students"; мин язучымын "I am a writer".

3°. The third person plural may optionally be a singular although the subject is a plural: таулар биек иде "the mountains were high".

5.62. Direct object complement

A direct object complement has either the basic, suffixless form or the form of the direct object with the pure-relational suffix /-nE/.

5.621. Direct object complement without suffix

Substantives which denote indefinite objects void of any characteristic features making them distinguishable from other, similar objects, appear in a suffixless form: бала китап укый "the child reads a book"; мин хат яздым "I wrote a letter".

5.622. Direct object complement with the suff. /-nE/

1°. Substantives have the suffix when the direct object is definite, i.e., when it has some characteristic features, an attribute, etc.: бу мәкаләне син әлбәттә укып чыгарга тиешсең "thou must by all means read this article".

2°. The reflexive and interrogative nouns take always the suffix /-nE/: ул үзен һәлак итте "he has destroyed himself"; син кемне күрдең "whom did you see?"

3°. Proper names always take the suff. /-nE/: мин Нәфисәне күрдем "I saw Näfisä".

4°. Pronouns take always the suff. /-nE/: ул мине күрде "he saw me"; мин аны күрдем "I saw him".

5°. A clause with a participle: participle with the suff. /-nE/ and the actor indicated by a nominative indicate that the predicate affects the action of the participle: мин син укыганны яратам "I like your reading" = "I like the fact that you read" (not "what you read", the latter being expressed by a phrase with a participle, as a head, provided with a possessive suffix and the actor indicated by a noun [pronoun, etc.] with the pure-relational suffix /-nEŋ/: мин синең укыганыңны яратам "I like what you read").

5.63. Adverbial complement

An adverbial complement may be an adverb, a noun provided with a pure-relational suffix (including the direct-object suffix /-nE/), a noun in the nominative (basic form), a noun or pronoun with a postposition, a participle phrase with a participle provided with a pure-relational suffix, gerund, gerundial phrase.

1°. Adverb: балык тиз үрчи "fish procreate fast".

2°. Adjective with a pure-relational suffix: ул яңадан буяды "he repainted" ("painted anew").

3°. Noun with a pure-relational suffix: без мәктәптә укыйбыз "we study in school"; Зәйнәптән китапны алдым "I took the book from Zäynäp".

4°. A particular case is the suffixless direct-object form of a noun which functions as adverbial complement indicating time: ул бер ай практикада булды "he was on practical work for a month"; үткән ел әлеге суга баткан Нәфисәнең анасы "the mother of above mentioned Näfisä who (i. e., Näfisä) had drowned last year"; һәр көн, иртәле-кичле салкыннар булып тора "every day, morning and evening, cold weather stays".

5°. A particular case is the direct-object form provided with the suffix /-nE/ which indicates a definite time: бер көнне яр буендагы куаклыкка җиләккә киттек "one day we went for berries to the bushes which are on the bank".

6°. A particular case is the suffixless direct-object form which serves to indicate the object into which the direct object is transformed: мине местком председателе итеп сайладылар "they elected me the chairman of the local".

7°. Noun or pronoun with a postposition: мәктәп өчен "for the sake of the school"; әти белән "with the father"; синең өчен "for thy sake".

8°. Participial or verb-nominal phrase with a participle cr verbal noun respectively, provided with a pure-relational suffix and with or without a postposition: мин мәктәпкә укырга килдем "I came to school in order to study"; мин үземнең этем белән бергә чокыр буйлап күтәрелгәндә, эссе июль көне иде "it was a hot day of July when I, together with my own dog, was climbing the ravine"; ярышның үзен тасвир итүгә керешүдән элек үземнең хикәямдә катнашучыларның һәркайсы турында берничә сүз әйтү артык булмас дип саныйм "before I proceed to the description of the competition itself, I believe it not to be superfluous to say some words about each of the characters in my tale".

9°. Gerund: ул тырышып эшли "he works industriously" (lit.: "he works making efforts"); кич якынлашып килә "the evening is approaching" (lit.: "the evening comes becoming near"); юл буенда җимеш бакчалары яшәреп калалар "by the side of the road orchards" (lit.: "fruit gardens") are covered with green foliage" (lit.: "remain being green").

10. Gerundial phrase: хатны укыгач, Зәйнәп бик шатланды "after having read the letter, Zäynäp greatly rejoiced"; поезд килгәнче утырабыз "we sit before the train comes"; яңгыр туктагач, балалар урамга чыктылар "when the rain stopped

the children went into the street"; җил басылып, һава тәмам тынычланды "the wind calmed down and the weather became completely calm"; буран басылганчы, юлга чыкмый тордык "we still did not go on the road before the blizzard had stopped"; машина килеп туктаганны күргәч тә, Нәсимә апа ашыга-ашыга аны каршы алырга йөгерде "having seen that the engine had arrived and stopped, Aunt Näsimä ran quickly towards it in order to receive it"; биш сум чамасы акча җыелгач "when there had accumulated money [amounting to] about five roubles"; ул чишенеп яңадан киенгәнче, тагын бер сәгать үтте "another hour passed before he redressed".

## Notes

1. This is the reason why such nouns as /östendä/ "on top, on" are not regarded as true postpositions, because the latter never take possessive suffixes.

# 6. CLAUSE-STRUCTURE

6.0. A clause may consist of one or more words or phrases: килдем "I came"; көн кояшлы "the day [is] sunny"; сез Маратны беләсез? "do you know Marat?". Clauses may be joined to other clauses, thus forming compound clauses. Clauses are classified in full and minor clauses.

## 6.1. Full Clauses

Full clauses have as their basic element the predicate. The latter may occur with or without subject.

With subject: мин күрдем "I saw".

Without subject: күрдем "[I] saw".

### 6.11. The predicate

The predicate has as its center:

1°. A verb, including compound verbs and compound tenses: күк йөзе яктыра "the sky (lit.: "the face of the sky") brightens"; мин авыруга ярдәм иттем "I helped the sick person"; мин китапны алып килдем "I brought the book"; самолёт очып килә "an airplane is flying"; эш бетеп килә "the work is going to an end"; мин яңгырдан бөтенләй чыланып беттем "I became completely wet from rain"; хат язасы идем "I intended to write a letter"; адресын белсәм, хат язар идем "if I knew his address, I would write [him] a letter".

2°. A noun, adjective, pronoun, verbal noun, participle or equivalent in nominative. Such a clause has the meaning "identity of things indicated by the subject and predicate".

A. With a verb as a copula: Вәли инженер булган "Wäli has become an engineer"; Мохтар укытучы булыр "Mokhtar will be a teacher"; кичә көн матур иде "yesterday the weather (lit.: "the day") was beautiful"; хат язасы идем "I intended to write a letter".

B. With a predicative suffix (mostly with a zero-suffix of the third person): мин инженермен "I am an engineer"; алар студентлардыр "they are students"; язучысың "thou art a writer"; сиз укучыларсыз "you are students".

C. Without verb or predicative suffix: мин — большевикларның фронт штабы разведкасыннан Карабанов "I [am] Karabanov from the intelligence of the headquarters of the Bolshevist front"; әйткән сүз — аткан ук "a spoken word [is] an arrow which has been shot"; безнең өйдә без җидәү "we are seven in our house"; Сарык абзый, син көчлерәк "Uncle Sheep, thou art stronger"; ә колхоз кемнеке ? "but whose [is] the collective farm?"; колхоз — синеке дә, минеке дә "the collective farm is both thine and mine".

3°. A noun, pronoun or equivalent with a pure-relational suffix: мин Казаннанмын "I am from Kazan".

4°. Interjection: ул аяклар, мин сиңа әйтим, тратта-та да тратта-та "those feet, I tell you, [make] tratta-ta and tratta-ta" (sounds of clattering).

A predicate is modified as a whole by an adverb: бу китап бик яхшы "this book is very good".

6.12. The subject

The subject may be a noun, a substantivized adjective, a pronoun, numeral or verbal noun or participle, a phrase or even a clause.

The subject is in nominative, i.e., without pure-relational suffix: Марс мәктәпкә китте "Mars went to school"; бакчада кошлар сайрыйлар "birds sing in the garden"; җир йомшартылды "the earth was made soft"; Вәли бик матур шигырь язган "Wäli has written a very beautiful poem"; бүген һава җылы "today weather is warm"; Тукай — шагыйрь "Tukai is a poet"; Азат тырышып укый, ул — пионер "Azat studies industriously, he [is] a pioneer" (i.e., a boy scout).

6.121. Agreement between the subject and predicate is always obligatory in actor-action clauses when the predicate is a verb-form: мин кичә җыелышка калдым "I remained yesterday at the meeting".

6.122. Agreement in person is not obligatory in equational clauses, when the predicate is a substantive or adjective: мин колхозчымын or мин колхозчы "I [am] a collective farmer"; без колхозчыбыз or без колхозчы "we [are] collective farmers".

6.123. There may be no agreement in number in the following cases:

1°. In actor-action clauses the verb may be a singular when the subject is the pronoun алар "they" or a substantive in a plural-form: алар кайттылар or алар кайтты "they returned"; ашлыклар

үсте "the crops grew"; башаклар пеште "the ears ripened"; таулар биек иде "the mountains were high"; аның төньяк өлешенә Волга, Урал, Терек һәм Кура елгалары агып төшә "in its northern part the rivers Volga, Ural, Terek, and Kura join it" (i. e., the Caspian Sea).

2°. In equational clauses the predicate may be a singular, although the subject is a plural: без колхозчыбыз or без колхозчыларбыз "we [are] collective farmers".

6.124. Compound subjects

1°. A verbal predicate (i. e., a verb form functioning as a predicate) may be a singular although the subject is a compound subject of the third person and includes even plural-forms: безнең армиябез (sing.), батыр очучыларыбыз (plur.), көчле флотыбыз, җитез кавалериябез ватаныбызны эчке һәм тышкы дошманнардан саклый (sing.) "our army, our valiant fliers, our mighty navy, our mobile cavalry protect (sing.) our homeland from the internal and external enemies"; искән әкрен җил белән яфрак, агачлар калтырый "the leaves, the trees are shaking in the slow blowing wind".

2°. In equational clauses the noun of the predicate is a plural when the compound subject consists of proper names: Нәфисә һәм Мохтар укучылар "Näfisä and Mokhtar [are] students".

3°. The predicate is a plural first person when the compound subject is a pronoun of the first and second person: мин һәм син колхозда эшлибез "I and thou [we] work in a collective farm".

4°. The predicate is a plural second person when the subject phrase contains the second person pronoun and the third person pronoun or a substantive: син һәм ул яхшы укучысыз "thou and he are good students"; син һәм Нәфисә яхшы укыйсыз "thou and Näfisä study well".

6.125. Pause (||)

In some instances the pause is an important mark of the subject.

1°. After a noun which is followed by a noun: Волга Днепрдан озынрак /wolga || dneprdan ozïnrak/ "Volga [is] longer than the Dnepr"; Азат Илдардан олырак /azat || ildardan olïrak/ "Azat [is] older than Ildar".

2°. After a demonstrative pronoun: бу — китап /bu || kitap/ "this is a book" (without pause, i. e., /bu kitap/ is "this book", i. e., attribute + head).

3°. After a substantivized adjective: кара шешә эчендә иде /kara || šešä ečendä ide/ "ink was in the bottle" (without pause, i.e., /kara šešä ečendä ide/ is "was in a black bottle").

4°. After a numeral adjective: ун тапкыр ун — йөз /un tapkïr un || yöz/ "ten times ten [is] hundred".

5°. After a participle: туры әйткән котылыр, ялганлаган тотылыр /turï äytkän || kotïlïr, yalganlagan || totïlïr/ "he who spoke the truth will be saved, he who lied will be caught"; тырышкан табар /tïrïškan || tabar/ "he who made efforts will find".

## 6.2. Types of Intonation and Clause-Structure

There are three main types of clause-intonation according to which clauses may be classified.

### 6.21. Declarative clauses

1°. Falling intonation: the pitch is higher at the beginning of the clause and falls on the stressed syllables of the successive phrases to a lower point on the stressed syllable of the last phrase. This type of intonation indicates that the clause is the last in the sentence /./. As example may serve the second clause of the following sentence: Эт санитар отряд янына чапты һәм безнең санитарларны китерде. Санитарлар мине үлемнән коткардылар ⁻‒_ /sanitarlar mine ülemnän kotkardïlar/ "the medical aids saved me from death".

2°. Falling-level intonation (comma intonation): the pitch is high at the beginning of the clause, falls and remains level. This type indicates that a further clause is to follow in the same sentence. As example may serve the first clause of the sentence given above: /et || sanitar aträd-yanïna čaptï häm bezneŋ sanitarlarnï kiterde/: ⁻‒_ _ _ _ _ "the dog ran to the medical platoon and brought our medical aids".

6.211. The normal order is: subject + predicate: кошлар сайрыйлар "birds are singing"; яз җитте "spring has come".

Likewise, the complement usually precedes the predicate and follows the subject: бала китап укый "the child reads a book".

6.212. In poetry and in political slogans the order may be reversed. In such instances the elements at the beginning of the clause are felt to be emphasized: яратам мин киң кырларны "I <u>love</u> the wide fields"; яшәсен очучылар "long live the fliers!".

6.213. In negative clauses the predicate has a negative.

1°. The predicate is a negative verb-form: мин аны күрмәдем "I did not see him".

2°. The predicate may be a participle with түгел "not": ул киләчәк түгел "he will not come"; яшлык уңган түгел "the crops have not grown".

3°. The predicate may be a noun or adjective with түгел : бу агач түгел /bu || agač tügel/ "this is not wood"; бу китап юнь түгел "this book is not inexpensive"; ул кеше миңа таныш түгел "that person is unknown to me".

4°. The predicate may be the negative noun юк: аны һич күргәнем юк "I have never seen him" (lit.: "him at all my having seen not", i.e., "there has never been my seeing him").

5°. A predicate with a double negative is positive: яшлык уңмаган түгел "the crops have not not grown", i.e., "the crops have grown".

6.22. Interrogative clauses

Two types of interrogative clauses occur.

1°. With rising intonation: clauses in which the predicate is questioned the latter takes one of the interrogative particles or may not take it. In such clauses the pitch is high on the last accented syllable of the clause: _ _ ‾ /sez maratnï beläsez/ сез Маратны беләсез? "do you know Marat?"; _ ‾ /zäkiyä kildeme/ Зәкия килдеме ? "did Zäkiyä come?"; _ ‾ /yaŋgïr tuktadïmïney/ яңгыр туктадымыни ? "has the rain really stopped?".

2°. With falling intonation. Clauses which contain an interrogative word such as /kem/ "who?", /närsä/ "what?", /nindey/ "what kind of?", /kayda/ "where?", /kayčan/ "when?", etc. functioning as any element other than predicate.

A. With falling intonation. Clauses of two elements (subject + predicate): кем бар ‾ _ /kem bar?/ "who is [it]?"; нәрсә бар ‾ _ /närsä bar?/ "what is [it]?"; ни булды ‾ _ /ney buldï?/ "what has happened?".

B. With rising-falling intonation. Clauses of more than two elements: the intonation rises on the accented syllables, the pitch reaches its peak on the accented syllable of the interrogative word and falls: кичә сезгә кем килде _ ‾ ‾ _ /kičä sezgä kem kilde?/ "who came to you yesterday?".

6.23. Exclamatory clauses

The pitch remains level on all stressed syllables and the stress is stronger than usual /!/: _ _ _ _ их, нинди матур чәчәк! /ix, nindey matur čäčäk!/ "oh, what a beautiful flower!"; дәфтәрне пычратып язмагыз! /däftärne pïčratïp yazmagïz!/ "do not soil the notebook!" (lit.: "do not write soiling the notebook!"); суны кирәксезгә коймагыз! /sunï kiräksezgä koymagïz!/ "do not pour water unnecessarily!".

6.3. Minor Clauses

Minor clauses are: 1. fragmentary (incomplete) clauses which can be expanded by adding other elements which are lacking, or 2. interjectional clauses.

6.31. Fragmentary clauses

Fragmentary clauses are:

1°. Substitutes for complete clauses in vivid descriptions in which images follow each other in a swift succession: Якшәмбе көн. Иртә сәгать уннар чамасы "Sunday. Approximately ten o'clock in the morning" (for: "it is Sunday, it is approximately ten o'clock in the morning"); Карлы яңгыр. Окоп. Төн. Суык. "Rain with snow. A trench. Night. Cold".

2°. Fragmentary clauses in dialogue, questions and answers: Итең бармы? —Юк! "Do you have meat?" —"No!"; Улым, Сәлимҗан кайсы йортта тора? —Нинди Сәлимҗан?—Балтачы Сәлимҗан. —Әнә теге йортта. "My son, in what house does Selimjan live?"—"What Selimjan?"—"The hammerer Selimjan."—"There, in that house."

3°. Vocatives: Иптәш Мансуров! "Comrade Mansurov!".

4°. Greetings, book titles, contents of captions, signboards, etc.: Сәлам! "Greetings!"; Таң атканда "At down." (title of a novel by Kamal); Урта Мәктәп "Secondary school" (a signboard).

6.32. Interjectional clauses

Interjectional clauses occur usually with exclamatory intonation.

1°. Phrases of normal construction: Менә кайда дөнья! "So this is where the world is!".

2°. Special words such as interjections: Иhи! — диде Гариф "Aha," said Garif".

## 6.4. Combination of Clauses

There are two types: coordinate and subordinate clauses.

6.41. There occur two types of coordinate clauses: 1. without conjunctions and 2. with conjunctions.

6.411. Coordination without conjunctions: ашлыклар үсте, башаклар пеште "the crops grew, the ears became ripe"; агым су ялтыравыклы күксел бозга уралып ята, урманлык матур гына акка буяла, сахраларны да ап-ак чаршау каплап ала "the streaming water whirls on the sparkling bluish ice, the wooded country acquires a beautiful white color, an absolutely white curtain covers even the [wide] space"; җир яшәрмәс, гөл ачылмас, төшми яңгыр тамчысы "the earth does not become green, the rose does not unfold, the rain drops do not fall".

6.412. Coordination with conjunctions

The conjunctions used in coordinate clauses are those enumerated in 3.71 and the particle /dÄ/ vide 3.81: җил басылды, һәм көн матурланды "the wind stopped and the day became beautiful"; яз килер, һәм сез тагын да алма, кыяр бакчаларында дүрт аякланып кунакка йөрерсез "the spring will come and you will again go visiting, on four legs, in the orchards and vegetable gardens (lit.: in the apple and cucumber gardens)"; менә хәзер арба кузгалыр да, бу йөз белән бу күзләр ераклашырлар, һәм, ниһаять, бөтенләй күздән югалырлар "look, now the carriage will move and these eyes, together with this face, will become distant and, finally, disappear completely from the view"; бүре дә тук булсын, куй да бөтен булсын! "let the wolf be satiated and the sheep intact!"; урамда беркем дә юк, хәтта этләр дә өрми "there is nobody in the street and the dogs do not even bark"; ни аяклары төзелми, ни бер кулы эшкә ярамый "his feet do not become better and none of his hands is suitable to work"; кич белән командир тагын килеп китте, ләкин аның шиге һаман хәл ителми калды "in the evening, the commander came again but his doubts remained all the time, [the problem] not being solved".

6.42. Subordination

Clauses are subordinated by means of the following subordinating conjunctions:

1°. /čönkey/ "because": Зәкия барлык фәннәрдән 5 билгесе алды, чөнки ул бик тырышып укый "Zäkiyä received the grade mark 5 in all subjects, because he studies very industriously (lit.: because he studies making great efforts)".

2°. /güyä/ "as if": Караборын башын түбән иде, гүя Әйдүкнең кайгысын белгән кебек, әкрен генә атлап килә иде "Karaborïn drooped his head as if he had known Äydük's sorrow, and he came pacing slowly"; Сәмигулла абзый бүген йокысында да гаять ләззәтле төш күрде, гүя ул зур бер бакчада йөри имеш "Uncle Sämigulla had (lit.: saw) today a very pleasant dream in his sleep as if he was walking in a large garden"; агачлар җил уңаена башларын иялар, гүя алар кемнедер сәламләп каршыйлар "the trees are bowing their heads in the direction of the wind as if they are welcoming and greeting somebody".

3°. /ägär/ "if, when": әгәр шатлык, бәхет килсә, хәзерләрсез бүләргә сез, әгәр ямьсез вакыт килсә, хәзер миннән көләргә сез "when joy and happiness comes, you will be ready to share it [with me when unpleasant times come you will be ready to laugh at me"; әгәр дә ул үзенең киләчәгенә ышана икән, яланкул белән таулар актара ала "if he believes in his future, he will be able to dig away mountains with his bare hands"; әгәр дә кешене кеше итү безнең кулдан килә торган булса иде, без инде аны алтыннан ясап куйган булыр иде "if it depended on our own hands to make a person a human being, we would make him of gold".

4°. /key/ [kī] "that": билгеле ки, безнең завод үз эшендәге кимчелекләрне һаман бетер бара "it is known that our plant always corrects (lit.: liquidates) the defects in its work"; чәчүлек ашлыкны шундый җентекләп чистатырга кирәк ки, анда бер генә чит орлык та калмасын "it is necessary to clean the seeds so thoroughly in order that there does not remain a single foreign (i.e., of another kind) seed".

6.421. The direct discourse is juxtaposed to the main clause and connected with the verb "to speak" (verbum dicendi) other than ди- by means of the gerund дип "saying": нигә җибәрмәскә, җибәрер идем, — диде теге малай "why not send? I would send," said that lad"; бездә хәзер кич, — дип җавап бирер иде "now

we have evening, he answered"; сездә хәзер көннәр нинди, һавалар ничек? — дип сораса "when he asked, 'what are the days presently in your country? (lit.: at yours), what is the weather?'"; "Нәрсә бар?". "Кем бар?". "Ни булды?" —дип кычкыра башладылар "What is there?", "Who is there?", "What has happened?", they started to shout.

# *II. TEXTS*

The texts given in the chrestomathy were taken from the following sources:

1. Татар халык авыз иҗаты from М. Гайнуллин, Х. Ярми, Татар әдәбияты, 8нче класс өчен дәреслек, Татарстан Мәгариф Министрлыгы раслады, Дүртенче басма, Таткнигоиздат, Казан, 1957, pp. 16-18, 35-36.

2. Камыр батыр and 3. Ике мулла белән бер мужик from Татар әдәбиятыннан хрестоматия, Татар урта мәктәпләренең VIII классы өчен, Төзүчеләре: М. Гайнуллин һәм Х. Ярми, 8нче басма, Татарстан Мәгариф Министрлыгы раслады, Таткнигоиздат, 1957, pp. 3-12.

4. К. Насыйри новеллаларыннан үрнәкләр, ibid., pp. 27-33.

5. Хиссияте миллия and 6. Мәкаләи махсуса by Габдулла Тукай from Әдәбияттан хрестоматия, Урта мәктәпнең 9нчы классы өчен, Төзүчесе Х. Хәйри, Татарстан Мәгариф Министрлыгы тарафыннан раслады, Җиденче басма, Таткнигоиздат, Казан, 1957, pp. 91-100.

7. Ярлылар яки өйдәш хатын by Мәҗит Гафури, ibid., pp. 189-199.

8. Татар кызы by Фатих Әмирхан, ibid., pp. 308-317.

9. Габдрахман Ильяси (a biographical article) from М. Гайнуллин, Х. Ярми, Татар әдәбияты, pp. 155-161 (full bibliogr. information vide 1.).

10. The poems Татар яшьләре and Хөрмәтле хөсәен ядкаре from Әдәбияттан хрестоматия (full bibliogr. information vide 5.), pp. 90-91.

# ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

**В. И. Ленин халык авыз иҗаты турында**

Бөек юлбашчыбыз В. И. Ленин халык авыз иҗаты әсәрләренең тарихи һәм художество кыйммәтләренә бик зур бәя бирде. Вл. Бонч-Бруевич «Поэзия турында Ленин» исемле истәлегендә Владимир Ильичның халык шагыйрьләре иҗатына һәрвакытта да аерата зур игътибар белән караганлыгын әйтә.

В. И. Ленин революцион җырларны бик ярата һәм аларны җырлаганда һәрвакытта үзе дә катнаша торган булган. Ул революцион эчтәлекле шигырьләрне дә бик яратып укыган.

Владимир Ильич халык иҗаты әсәрләренең барлык төрләре белән дә бик нык кызыксына. Ул мәкаль һәм әйтемнәрнең иң матурларын, халык арасында бик нык таралганнарын үзенең хезмәтләренә кертә, алардан бик оста һәм урынлы файдалана.

В. И. Ленин халык иҗаты әсәрләренә халыкның дөньяга карашын, аның уй һәм теләкләрен өйрәнү өчен кирәкле һәм мөһим материал дип карый. Халык авыз иҗаты әсәрләре социаль политик ноктадан каралырга тиеш, — ди ул һәм әдәбият тарихчылары алдына халык иҗаты материаллары нигезендә «халыкның теләкләре һәм өметләре турында бик яхшы хезмәтләр язарга тиешләр» дигән бурычны куя.

В. И. Ленинның өйрәтүләрен тормышка ашыручы Коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәтенең халык иҗатын үстерүгә бик зур әһәмият бирүләре нәтиҗәсендә, Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң безнең илебездә халык поэзиясенең үсүенә, аның өйрәнелүенә

бик күп шартлар тудырылды. Октябрь социалистик революциясеннән соң, СССРдагы башка халыкларның авыз иҗаты кебек үк, татар халык авыз иҗаты да урта мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында аерым фән итеп укытыла. Халык иҗаты әсәрләрен халык теленнән язып алу өчен һәр елны фәнни экспедицияләр оештырыла, җыйналган материаллар нигезендә төрле җыентыклар чыгарыла һәм хезмәтләр языла.

Совет хөкүмәтенең күренекле җырчылар, былиначылар һәм әкиятчеләрне орденнар белән бүләкләве, безнең илебездә халык авыз иҗаты җәүһәрләрен туплау һәм өйрәнү эшенә зур мөмкинлекләр бирелүе — болар халык талантларын үстерү турында Коммунистлар партиясенең көндәлек кайгыртуы буенча эшләнәләр. Әнә шуңа күрә бездә хәзер халык иҗаты тирән эчтәлеккә, художестволы матурлыкка ирешүе, аның чын-чыннан чәчәк ату чоры башланды.

**А. М. Горький халык авыз иҗаты турында.**

Пролетариатның бөек язучысы А. М. Горький, халык авыз иҗатын бик күп еллар буена өйрәнү һәм туплау белән бергә, халык поэзиясе материалларын үз әсәрләрендә дә гаять киң күләмдә файдаланды. Ул халык иҗатының идея һәм художество үзенчәлекләре турында зур һәм кыйммәтле фәнни хезмәтләр язып калдырды. «Шәхеснең җимерелүе» исемле мәкаләсендә, «Мең дә бер кичә» исемле җыентыкка язган сүз башында, совет язучыларының Беренче Бөтенсоюз съездында ясаган докладында һәм башка хезмәтләрендә Горький халык авыз иҗатының тарихи һәм художество әһәмиятен тирәнтен аңлатты. «Халыкның авыз иҗатын белми торып, хезмәт халкының чын тарихын белү мөмкин түгел... Фольклор иң борынгы заманнардан бирле һич чигенмәстән һәм үзенә бертөрле рәвештә тарихка юлдашлык итеп килә», — диде ул.

А. М. Горький: борынгы халык иҗаты әсәрләренең төп мәгънәләре «хезмәт кешеләренең үз эшләрен җиңеләйтергә, аның җитештерүчәнлеген көчәйтергә, дүрт аяклы һәм ике аяклы дошманнарга каршы коралланырга, шулай ук сүз көче белән, төрле «ырымнар» ярдәме белән кешеләргә дошман булган стихиячел табигать күренешләренә йогынты ясарга омтылуларына кайтып кала», — ди һәм авыз иҗаты әсәрләренең тирән эчтәлекле, югары художестволы булуларының төп сәбәбе — ха-

лыкның талант иясе булуында икәнлеген күрсәтә. Кеше «...үзенең тормышына нинди дә булса матурлык кертергә тырыша. ...Кеше — художник. Моның шулай икәнлегенә безне, «кечкенә» кешеләр тарафыннан чыгарылып, телдән телгә сөйләнеп йөри торган, халык иҗаты булган мифлар, әкиятләр, легендалар, хорафатларга ышанулар, җырлар, мәкальләр һәм башкалар ышандыра. Болар барысы да — «кечкенә» кешеләр иҗаты, һәм боларның барысында да, гәрчә аларның күпчелегендә инде искергән карашлар булса да, чиксез күп матурлык бар, боларга хисапсыз күп буыннарның хезмәт тәҗрибәсе салынган. Капиталистик строй «кечкенә» кешеләрдә художниклык һәм иҗат сәләтләрен үтерде, бу строй талантларга урын да, җәелергә һәм чәчәк атарга мөмкинлек тә бирмәде», — ди А. М. Горький.

А. М. Горький үзенең халык поэзиясе турындагы хезмәтләрендә халык авыз иҗаты әсәрләрендә образларның бик нык эшләнү мәсьәләсенә тукталып: «Геройларның иң тирән һәм ачык, сәнгать ягыннан камил эшләнгән типлары фольклор тарафыннан, хезмәт халкының телдән сөйләнә торган иҗаты тарафыннан барлыкка китерелгәннәр», — ди. Ул халык иҗаты әсәрләре теленең сафлыгына һәм байлыгына да гаять зур бәя бирә, язучыларны халык поэзиясе теленнән өйрәнергә чакыра.

**Халык авыз иҗаты әсәрләренең төрләре һәм жанрлары.**

Халык авыз иҗаты әсәрләре ике зур төргә — эпик һәм лирик төргә — бүленәләр. Эпик төргә мифлар, легендалар, әкиятләр, бәетләр; лирик төргә йола фольклоры, мәкальләр, табышмаклар һәм лирик җырлар керә.

**Совет чоры халык җырлары.**

Бөек Октябрь социалистик революция халыкның дөньяга карашын нигездән үзгәртте. Бу, үз нәүбәтендә, халык иҗатына бөтенләй яңа идеяләр кертте. Элек хыялда гына яшәгән нәрсәләрнең социалистик револю-

циядән соң чынбарлыкка әверелүе халык иҗатының эчтәлеген яңартты. Халык совет тормышының матурлыгы турында җырлый. Революциянең беренче көннәреннән үк, гражданнар сугышы окопларында туган әсәрләрдән алып, халык поэзиясендә совет төзелешенең җиңү тантанасы җырлана башлады. Элекке авыр тормыштагы кайгы-хәсрәт, халыкның моң-зарын чагылдырган җырлар урынына, Октябрьдан соң илне индустрияләштерү, авыл хуҗалыгын коллективлаштыру кебек зур темаларны, яңа, социалистик тормышның барлык якларын яктырткан җырлар иҗат ителде. Октябрьдан соң халыкка, элекке вакытлардагы кебек, әллә нинди геройлар эзләргә, фантастик геройлар турында хыялланырга туры килмәде.

Бөек Октябрь социалистик революциянең җиңеп чыгуына В. И. Ленин җитәкчелек итте. Менә шуның өчен дә бөек Ленин образы халык күңелендә хезмәт ияләренең күптәнге теләк һәм өметләрен тормышка ашыручы реаль герой булып гәүдәләнде. Дошманнарны тар-мар итүче Кызыл Армиянең барлык җиңүләрен халык революциянең беренче көннәреннән үк Коммунистлар партиясе һәм бөек Ленин исеме белән бәйләп җырлады һәм шул турыда йөзләрчә җырлар иҗат итте. Гражданнар сугышы фронтларында Совет илен батырларча яклаучы геройлар — Ворошилов, Буденный, Фрунзе, Чапаев һ. б. турында халык бик күп санда җырлар һәм бу полководецларга кайнар мәхәббәт белән сугарылган истәлекләр тудырды.

Совет халык авыз иҗаты әсәрләрендә безнең илдә булган барлык уңышлыклар безнең бөек партиябез һәм Ленин образы белән бәйләп җырлана.

Советлар Союзы Конституциясенә багышланган җырларда халыкның Коммунистлар партиясенә булган кайнар мәхәббәте, чын күңелдән әйтелгән рәхмәте яңгырый. Коммунизмга бару юлындагы җиңү байрагы булган Советлар Союзы Конституциясен халык алкышлап каршы алды һәм шул шатлыгын үзенең җырларында чагылдырды.

Халыкның Коммунистлар партиясенә һәм Совет дәүләтенә булган чиксез зур мәхәббәте Бөек Ватан сугышына карата иҗат ителгән җырларда тагын да ачык чагылды.

# ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

## ӘКИЯТЛӘР.

### КАМЫР БАТЫР.

Борын-борын заманда, кәҗә команда, әби-бабай тумас борын, эти белән икәү генә торган чагында, бар иде бер карт белән карчык. Аларның балалары юк иде, шуңар кайгылары бик зур иде.

Бер заман болар исәпләделәр, уйладылар да камырдан бер бала сыны ясап куйдылар. Әби чыгып китте сыер саварга, бабай чыгып китте утын ярырга.

Керсәләр, исләре китте, акыллары таралды: камыр сыны, малай булып, кәҗә бәтиләре белән уйнап йөри.

Камыр малай төн үсә, көн үсә, ай үсәсен көн үсә, ел үсәсен ай үсә. Бабай ясап бирде, ди, моңа шартаяк. Малай бер таянган иде, ди, шартаяк шарт итеп сынды, ди. Бабай төшеп китте, ди, тимерчедән ясатты, ди, моңа тимер шартаяк. Малай бер көнне урамга чыга — бер малайның аягын сындырып керә, икенче көнне чыга — икенче малайның муенын сындырып керә, ди.

Шуннан соң авыл халкы җыелып бабайга әйтәләр:

— Маласң малай төсле түгел, балаларны имгәтеп бетерә, теләсәң кая куй! — диләр.

Чыгып китә малай дөнья гизәргә. Атна китә, көн китә, ай китә, ел китә, бер саплам җир китә. Барып керә, ди, бу бер карурманга. Очрый, ди, моңа бер аягын тышаулаган кеше.

Камыр батыр сорый моннан:

— Нишләп тышаулադың син бу аягыңны? — ди.

Тегe кеше әйтә:

— Миңа болай да таманга килә әле, ди, аягымны ычкындырсам, мин күккә очам, минем арттан кош-корт та очып җитә алмый. — ди.

Камыр батыр моны үзе белән ияртеп китә, ди.

Баралар, баралар, ди, бара торгач, очрый, ди, боларга борын тишеген бармагы белән кысып утырган бер кеше.

Камыр батыр сорый моннан:

— Нишләп болай борын тишегеңне кысып утырасың? — ди.

Теге кеше әйтә:

— Миңа болай да таманга килә әле, ди. Югыйсә дөньяда зилзилә куба, бер борын тишеге белән өрдереп тә биш ташлы тегермән әйләндерәм мин, — ди.

Камыр батыр моны да үзе белән ияртеп алып китә.

Баралар, баралар, ди, болар. Очрый, ди, боларга эшләпәсен кырын гына салган ак сакаллы бер бабай.

Камыр батыр сорый моннан:

— Нишләп болай эшләпәңне кырын гына салдың? — ди.

Теге бабай әйтә:

— Миңа болай да таманга килә әле, ди. Мин эшләпәмне туры кисәм, күз ачмаслык буран чыга, басып кисәм, җир йөзенә ике илле боз ката, — ди.

Камыр батыр монысын да үзе белән ияртеп китә.

Баралар, баралар, ди, болар. Очрый, ди, боларга ук төзәп торучы тагын бер кеше.

Камыр батыр сорый моннан:

— Нәрсә атасың син болай? — ди.

Ук төзәп торучы әйтә:

— Ә-ә-ә-нә, күрәсеңме, теге тауның кабыргасында, моннан алтмыш чакрым җирдә, бер чебен утыра. Шул чебеннең сул күзен атып чыгараем, — ди.

Камыр батыр моны да үзе белән ияртеп китә, ди.

Тагын китәләр, ди. Беравык баргач, очрый, ди, боларга туфрак белән уйнып торган сакаллы бер кеше.

Камыр батыр сорый моннан:

— Нишләп болай уйныйсың? — ди.

Сакаллы кеше әйтә:

— Бу яктан сугам — бу якка тау өям, бу яктан сугам — бу якка тау өям, — ди.

Камыр батыр монысын да үзе белән ияртеп китә.

Барып җитәләр болар бер байга, сорыйлар моның кызын. Бай бик кире була, төрле хәйләләр кора.

— Минем кызым бай кызы, патша кызыннан ким түгел, сиңдәйләргә тиң түгел, ди. Әйдә, миннән булсын

яхшылык, ди, йөгерешчемне узсаң, бирсәм бирермен инде, — ди.

Китәләр йөгерешкә. Аягын тышаулаган егет алтмыш чакрым җирне бер-ике сикерүдә барып җитә дә, бай йөгерешчесе килеп җиткәнче дип, тау өстендә йоклап китә. Байның йөгерешчесе йөгереп мәйданга якынлашып килгәндә, теге һаман йоклаган була, ди, әле.

Камыр батыр әйтә:

— Ай-һай, ди, бай малае җиңә бит, ди. Ат эле тегеңәр, — ди.

Алтмыш чакрымнан чебеннең сыңар күзен атып алучы кеше атып җибәрә, йөгерешченең колак яфрагын чеметтереп ала. Йөгерешче уянып китә дә мәйданга бай йөгерешчесеннән алда килеп җитә, ди.

Хәзер бай алай итә, болай итә, боларны алдап чуен мунчага яба, ди. Әрдәнә-әрдәнә утын өйдерә, ут төртә, боларны яндырып үтермәкче була. Болар мунча эчендә пешә башлыйлар, ди. Камыр батыр бабайның эшләпәсен туры кидерә — мунча эчендә күз ачмаслык буран кузгала, ди. Алай да пешә башлыйлар, ди. Камыр батыр бабайның эшләпәсен бастырып кидертә — мунча стенасына ике илле боз ката, ди.

Икенче көнне бай, мунча ишеген ачып җибәрсә, шаккатып ботын чаба: болар барысы да исән!

Камыр батыр әйтә бу байга:

— Башымны катырма син минем, ди. Алыштанмы, салыштанмы? — ди.

— Алыштан да булыр, ди, бай әйтә, салыштан да булыр. Минем сиңа бирә торган кызым юк, көчең җитсә алырсың, — ди.

Китте алыш, китте егып салыш. Шундый алыштылар, шундый салыштылар — тигез җирләр түмгәк булды, түмгәк җирләр тигезләнде. Көн сугыштылар, төн сугыштылар, кич сугыштылар, бик озак сугыштылар. Бер борын тишеге белән өрдереп биш ташлы тегермән тарттыручы кеше борын тишеген сызгырттырып җибәрә — байның егерме кешесе очып китә. Туфрак белән уйнаучы бер яктан сугып җибәрә — утыз кеше күмелә, икенче яктан сугып җибәрә — утыз кеше күмелә. Камыр батыр күсәге белән бер селтәнә, утыз-кырык кеше кырылып бетә, ди.

Бай түзә алмаган, кызын бирергә булган, ди. Кызны Камыр батырга биргәннән соң утыз көн уен итеп, кы-

рык көн туен итеп, тумаган ала биянең итен пешерел, бик каты сыйланганнар, ди. Туйларында мин дә булдым, аш-суының чиге юк, бәлешләренең төбе юк, мичкә-мичкә бал куйганнар, үзләре чүмеч белән чумыралар, миңа сабы белән генә эләкте.

## ҮТКЕН ЕГЕТ.

Бер фәкыйрьнең өч улы була. Моның зур улы эш эзләп читкә чыгып китә. Атасы әйтә:

— Фәлән авылга барсаң, Мусага кермә, — ди.

Малай китә, теге авылга керә, Мусаның нәкъ үзенә очрый.

— Бабай, сиңа хезмәтче кирәк түгелме? — ди.

— Кирәк, — ди теге.

— Исемең кем?

— Муса.

— Юк, ди, егет әйтә, — әти Мусага керергә кушмады, — ди.

Малай туры урамнан барганда, Муса карт астагы урамнан әйләнеп тагы моның каршысына килеп чыга. Малай әйтә:

— Мин эш эзләп йөрим, кеше кирәк түгелме? — ди.

Муса әйтә:

— Кирәк, — ди.

— Исемең кем?

— Муса, — ди.

Теге егет:

— Бу авылда Мусадан башка кеше юктыр, ахры, ялланам инде, — ди.

Бу ялланды шул шарт белән: ачу китерештән. Муса әйтә:

— Сиңа ашаган саен бер чынаяк чәй белән бер телем икмәк булыр, ашыйсың да торып китәсең. Шуңар ачуың килсә, аркаңнан бер телем каеш телеп алырмын. Минем ачуым килсә, син минем аркадан телеп алырсың, — ди.

Ни булса булды, егет кереп эшкә тотынды. Кайтып ашарга утыра: бер чынаяк чәй, бер телем икмәк моңа. Дүрт-биш көн эшләгәч үк чыдарлык хәле калмады моның. Берконне егет, эштән кайтып, чәйне эчте дә чынаякны ыграк каплады. Муса әйтә:

— Әллә, улым, ачуың киләме бер чынаяк чәй эчеп, бер телем икмәк ашаганга? — ди.

Егет әйтә:

— Эшләп-эшләп туйганчы ашамагач, нишләп ачуың килмәсен? — ди. Малайның аркасын ачып, бер телем каеш ала да җибәрә бай моны.

Уртанчы малай да, барып, шулай ук булып кайта.

Инде кече малай китә. Тагы теге карт туры килә.

— Бабай, сиңа хезмәтче кирәк түгелме? — ди.

Бабай әйтә:

— Кирәк, — ди.

Егет әйтә:

— Исемең кем?

— Исемем Муса.

Егет әйтә:

— Миңа Муса кирәк иде дә шул, минем эзләп йөргәнем син идең, — ди.

Кереп эш башлый бу. Бер, ике, өч көн бик яхшы хезмәт итә. Бер телем икмәкне ашап, бер чынаяк чәйне эчә дә әйбәт кенә чынаягын каплый. Муса әйтә:

— Бер телем икмәк ашап, бер чынаяк чәй эчкәнгә бер дә ачуың килмиме? — ди. Егет әйтә:

— Юк, ачуым килми, — ди.

— Иртәгесен, ди Муса, күрше малайлар белән сарык көтәргә барырсың, бик яхшы эшлисең икән, — ди.

Болар сарык көтәргә баралар. Елгага төшеп, Мусаның бер симез сарыгын суялар да иптәшләре белән пешереп ашыйлар.

Кич кайта, өстәл арасына кереп утыра, бер чынаяк чәй эчә, чынаягын каплый да кузгала.

— Улым, ди. Муса, бер телем икмәк ашап, бер чынаяк чәй эчкәнгә ачуың киләме әллә? — ди. Егет әйтә:

— Юк, юк, бабай, ачуым килми, ди. Теге тирән елгада синең бер симез сарыгыңны суеп ашадык, бабай, синең ачуың килмиме? — ди, Муса:

— Юк, юк, — дигән була.

Муса хатынына әйтә:

— Бу малайны сарык көтәргә җибәрмик, ди, бу өйрәтер ахрысы безне, — ди.

— Бүген ат көтәргә бар, балам, — ди егеткә.

Икенче көнне ат көтәргә баралар. Мусаның бер симез биясен суялар да рәхәтләнеп тамакларын туйдыралар, тиресен сатып, чәй-шикәр алалар.

Кич кайта, өстәл кырыена утыра, бер чынаяк чәй эчә дә каплый, бер телем икмәкне ашый да торып китә.

Муса әйтә:

— Улым, әллә бер телем икмәк ашап, бер чынаяк чәй эчкәнгә ачуың киләмс? — ди.

— Юк, юк, ди егет, бүген синең бер симез биянне суеп ашадык әле. Синең ачуың килмиме соң? — ди.

— Юк, юк, — дигән була Муса, үзе «уһ-уһ», ди. — Алайса моннан соң йорт эше эшләрсең син, улым, — ди.

Беркөнне Мусага кунаклар килә.

— Улым, — ди, — кунаклар килде, бер сарык суй, — ди.

— Бабай, кайсын суйыйм? — ди.

Муса моңа күн бияләй чыгарып бирә:

— Шушыны ки дә шапылдат, кайсы сиңа караса, шунсын суй, — ди.

Малай, күн бияләйне киеп, абзарга кереп кулын шапылдаткан иде, сарыклар өркеп абзар почмагына җыелдылар да барысы да моңар карап тора башладылар. Тотынды бу сарыкларны кырырга. Бер сарыкны тунап алып керде. Муса әйтә:

— Ник озак маташтың, мал суйганың юк иде мәллә? — ди.

— Анда эш күп булды, — ди егет. — Сарыклар барысы да миңа карадылар, мин аларның барысын да суйдым, ачуың килмиме? — ди. Муса:

— Юк, юк, — дигән була, үзе «аһ-ваһ» килә.

Муса хатынына әйтә:

— Безне бетерде бу, маллардан да аерды, моны, диюләргә җибәреп, үтертергә кирәк, шунсыз котылып булмас моннан, — ди. Моңа әйтә: — Безнең урманда, фәлән күлдә, су атларыбыз бар, шуларны алып кайтып күрсәт, — ди.

Егет чыгып китә, күлгә барып җитә. Күл читендә һәйбәт яшь юкәләр үсә икән, юкә төшереп ала да тотына бу аркан ишәргә. Бер дию килеп чыга.

— Нишлисең? — дип сорый.

— Нишләгәнне күрәсең, — ди егет әйтә, — аркан ишәмен, күлегезне күккә күтәрәмен, — ди. Дию күлгә чума да алып чыга бер зур ишәк.

— Менә шушыны күтәреп күлне әйләнеп кил, — ди, — шуннан соң күлне күккә асуыңа ышанырмын, — ди.

— Әүвәл үзең күтәреп әйлән, — ди егет.

Дию ишәкне күтәреп китә дә, күлне әйләнеп, егет янына килә. — Хәзер син күтәр инде, — ди. Егет, арканнан нукта ясап, ишәккә кигезеп ала, өстенә сикереп менә дә — әйдә күл әйләнәсеннән чабарга! Биш минут эчендә күлне әйләнеп, дию янына килеп җитә бу. Дию күлгә чума, абыйсына төшеп әйтә:

— Абый, күл читенә бер адәм баласы килгән, күлегезне күккә асам дип әйтә, котым очты, — ди. Агасы да чыга. Егеткә әйтә:

— Монда нишлисең?

— Нишләгәнне күрерсең, күлегезне күккә ассам, — ди егет.

Дию күлгә чума да егерме потлы чуен алып чыга.

— Менә шушыны күккә атып җибәр, төшкән чагында җиргә төшерминчә кулга тотып, җиргә куй, — ди. Егет әйтә:

— Әүвәл үзең атып күрсәт, — ди. Дию тотып чөя чуенны, бик югары менеп китә. Төшкән чагында, кулы белән тотып җиргә куя.

— Я, син атып җибәр инде, — ди. Егет чуен герләң тоткасыннан тота да, башын кыйшайтып, бер болытка карап тора. — Я, ни карап торасың, нишләп җибәрмисең? — ди дию.

— Мин җибәрсәм, төшәрлек итмәмен, әнә болыт киләме, шуңа кыстырып җибәрермен мин, — ди. Дию әйтә:

— Дөньяда бар гербез шушы безнең, зинһар җибәрә күрмә, — ди. Бу, болытка карап, тагы якланган була:

— Җибәрәм булгач җибәрәм, калдырмыйм, — ди. Дию әйтә:

— Җибәрә күрмә, ни теләгең бар? — ди.

Егет әйтә:

— Минем теләгем шул: син энеңне алып чык та, мин сезгә атланып Мусага сезне күрсәтеп килим, — ди.

Дию энесен алып чыгып, бу — абыйсына атланып, тегесен җитәкләп, Муса авылына кайтырга чыгалар.

Урманны чыкканда юл буенда бер ауган имән бар икән. Егет әйтә диюгә:

— Әни, җиләккә килгәндә орчыгымны югалттым, дип әйткән иде, монда икән, моны күтәреп кайт инде син, ди. Диюнең коты оча. — Әнисенең орчыгы болай булгач, безне бер генә кабып йотар ул, — ди.

Бер су буеннан узганда ташландык тегермән ташы күрделәр. — Менә, ди егет әйтә, минем әнинең орчык

башы монда төшеп калган икән, ди, моны да алыйк, — ди. Берсе имәнне күтәрде, берсе тегермән ташын, кайталар болар.

Авылга да якынлаштылар. Муса, егеттән котылдык дип, капка төбенә чыгып карап йөри икән, бер түбәдән диюләр белән егетнең килеп чыкканын күрә. Коты чыга моның. Егет диюләрне ишек алдына алып керә, имән белән тегермән ташын куялар.

— Бабай, менә айгырларыңны алып кайттым, — ди егет, — кая куйыйм? — ди.

— Җибәр, улым, — ди Муса, — исәннәр икән, шуны гына белэсем килгән иде, рәхмәт сиңа, — ди.

Муса бик курыкты инде моннан.

— Ничек котылырга инде, — ди. Моны хәзер туйганчы ашата, ачуың киләме дип сорамый да. Кич белән моңа әйтә:

— Балам, син түбән өйдә йокларсың, — ди. Хатыны белән киңәшеп, бер зур казан белән су кайнаталар. Егет йоклагач, өстенә кайнар су коеп үтермәк булалар. Егет төшеп ята. Кайнар су коя башлаганда, читкәрәк китеп тора. Тегеләр түгеп беткәч, тагын урынына килеп ята.

— Инде үлгәндер, ди Муса, иртәгә җыештырырбыз, — ди.

Иртә белән Муса төшә дә:

— Улым, ни хәл? — ди. Бу йоклап яткан була. — Тынычсыз булмадымы, монда кеше кунганы юк иде, — ди.

— Юк, юк, бабай,— ди егет,— бер болыт килеп җылы гына яңгыр яуды, рәхәтләнеп тәннәрем, — ди.

Муса хатынына менеп әйтә:

— Ул, ди, җылы гына яңгыр яуды дип әйтә, гомердә үлөсе юк икән аның, башыбызга җитәр, ахрысы, — ди.

Иртә торып, хатыны юл азыгы пешерә башлый, йортны ташлап качыйк, дип уйлашалар болар. Шул көнне кич, ат җигеп, китәргә хәзерләнәләр. Юл азыкларын бер капчык белән тарантас артына бәйлиләр, бүтән әйберләрен дә салалар. Егет моны сизә дә, капчыкның азыгын бушатып, анда үзе кереп ята.

Муса белән хатыны, атка утырып, чыгып китәләр. Бик каты чабалар, барып-барып, ничә чакрымнар киткәч, бер су буена килеп җитәләр. Ай яктысы якты. «Котылдык тегеннән» дип, атларын туарып, ашап-эчеп, йокларга яталар. Егет, капчыктан чыга да, байның атын җигәргә тотына, алып китәргә җыена. Ара-тирә атка

кычкыргалап та куя. Муса башын калкытып караса, егет атын тарантаска җигеп китәргә тора. Егет әйтә:

— Бабай, атың белән тарантасынны алып киткәнгә ачуың килмиме? — ди. Муса кычкыра башлый:

— Мал-туарынны да бетереп, актык атынны да алгач, нигә ачуың килмәсен? — дип сикереп тора. Егет Мусаның аяк-кулын бәйли, үткен пычак алып, күлмәген күтәрә дә аркасыннан бер телем каеш ала:

— Бусы абзый өчен, — ди. Икенчене телеп ала: — Бусы уртанчы абзый өчен, — ди. Өченчене телеп ала: — Менә монысы үзем өчен, — ди.

## ИКЕ МУЛЛА БЕЛӘН БЕР МУЖИК

Борын-борын заманда ике мулла белән бер мужик юлга чыкканнар. Барганнар-барганнар да туктаганнар болар бер кунаклыкка [1], туктагач, ботка пешергәннәр. Ботканың уртасын чокырайтып, күп итеп май салганнар. Ашарга утыргач, муллаларның берсе, кашыгын алган да:

— Дин-шәригать юлы менә бола-а-а-й килә, — дип, ботка уртасындагы майны үз ягына агызып җибәргән. Икенче мулла, моны карап торган да:

— Безнең этинең тегермәне менә бу якка таба әйләнә торган иде, — дип, майны үз ягына агызган.

Мужик, карап-карап утырган да:

— Менә, муллалар, дөнья дигәнең гел үзгәреп тора, киләчәктә дөньяның менә шулай асты-өскә килер, — дип, табактагы ботканы бөтенләй болгатып бетергән. Муллалар бу юлы мужикны алдый алмаганнар.

Ярар. Икенче көнне болар тагын кунарга туктаганнар. Боларның бер пешкән казлары булган. Кичен йокларга ятканда үзара сөйләшкәннәр.

— Кем дә кем иң яхшы төш күрә, иртәгә казны шул ашар.

Иртән торгач, болар үзләренең төшләрен сөйли башлаганнар. Башта беренче мулла сөйләгән:

— Мин, — дигән, — төшемдә яшел чапан, ап-ак чалма киеп, хаҗга киттем, — дигән.

---

[1] Кунаклык — юлчылар туктап кунып китә торган йорт — квартира.

Аның төшен яхшыга юраганнар. Аннары икенче мулла сөйләгән:

— Мин, — дигән, — зур аккош булып, кыйбла ягына очып киттем, — дигән.

Моның төшен дә яхшыга юраганнар. Инде мужикка чират житкән. Мужик әйткән:

— Сезнең берегез яшел чапан, ап-ак чалма киеп хаҗга китте, икенчегез аккош булып очып китте. Мин: «Болар тиз генә кайта алмас инде, каз бозылып әрәм булыр», дип куркып, аны ашадым да куйдым, — дигән.

---

## К. НАСЫЙРИ НОВЕЛЛАЛАРЫННАН ҮРНӘКЛӘР

### ИСКЕ МӘДРӘСӘДӘ.

I

Берәү әйтте: «Бер хәлфәне күрдем, янында бер озын вә бер кыска таяклары бар, бер быргы, дәхи барабаны бар.

— Болар ни эшкә? — дип сорадым. Хәлфә әйтте:

— Бу авылда мин балалар укытып торамын. Балалар шаяралар, сабакларын укымыйлар. Миңа якынрак утырганнарын кыска таяк белән сугамын, ерактагыларын озын таяк белән сугамын. (Алар минем) сүземне тыңламыйлар, үземнең өстемә ташланалар. Аннан соң барабанны орамын, быргыны кычкыртамын, шуннан соң халык җыелып мине коткаралар, — диде».

---

[1] Автор аларны хикәятләр дип атый.

К. Насыйриның бу новеллалары 1880 нче елда басылган «Кырык бакча» һәм 1884 нче елда басылган «Фәвакиһел җөласә фил әдәбият» дигән китапларында бирелгәннәр.

II

Янә бер авылда бер өйнең ишеге төбендә бер хәлфәне күрдем, эт кебек өрер. «Бу ни хәл?» — дип туктадым. Күрдем, өйдән бер бала чыкты. Хәлфә ул баланы тотып алды, колагыны бөрды.

— Бу ни хәл? — дип сорадым.

Хәлфә әйтте:

— Мин балалар укытучы бер хәлфәмен. Бу бала бик усал, каршы. «Сабагыңны укы!» — дисәм, качып китә; өенә кердер дә чыкмый, эт белән уйный. Качан ки мин эт кебек өрсәм, «эт бар икән» дип чыгадыр да, тотып аламын, — диде.

III

Мәдрәсәдә бер шәкерт үзенең энесен куа: «Бар, фәлән, су алып кер, минем эчәсем килә», — диде, энесе бармады, тәкрар әйтте, бармады, чөнки энесе яткан иде. Боларның хәлфәләре бар иде, ул әйтте: «Бар син, фәлән, үзең миңа су алып кер, минем эчәсем килә», — диде. Ул шәкерт торды, су алып керде, хәлфәсенә бирде. Хәлфә әйтте: «Ярар, рәхмәт, үзең эч инде, мин эчмәймен», — диде.

## НАДАН МӨӘЗИН БЕЛӘН НАДАН МУЛЛА.

Бер мөәзинне манарада күрделәр, кулында «Иман шарты» бар, азанны «Иман шарты»ннан карап әйтә, имеш. Сорадылар: — Ник карап әйтәсең, азан сүзләрен күңелеңнән белмисенме? — диделәр.

— Мулладан сорагыз, — диде.

Муллага бардылар. Мулла ул вакытта ишек алдында икән. Барып: «Әссәламегаләйкем», — дип сәлам бирделәр. Мулла, сәлам алмыйча, өенә кереп китте дә бер китап алып чыкты, (шуннан) актарды-актарды да «Вәгаләйкем әссәлам», — диде.

— Хәер, мулласы да шулай икән, — дип киттеләр.

## СУФЫЙ.

Бәгъзе суфыйларга әйттеләр: «Җөббәнне[1] сат, акча булыр», — диделәр. Суфый әйтте: «Балыкчы кармагын сатса, ни белән балык тотса кирәк», — диде.

---

[1] Җөббә — мулла, ишан һәм суфыйлар кия торган озын кием.

## МУЛЛА КАЙГЫСЫ.

Берәү вафат булып, мирасыннан бер яхшы тунын бер муллага җибәрделәр. Ул мулла әйтте: «Вафат булганын ишетеп бик кайгырган идем, тунын күргәч, сөендем тагы», — диде.

## ЯРЛЫ КАЙГЫСЫ.

### I

Бер фәкыйрь үлем сырхавы хәлендә ятканда, әкърабасыннан (якыннарыннан)[1] янына җыелган адәмнәр: «И фәлән, хәлең начар, иманыңны әйт», — дигәч, ул бичара: «Һай, шул үлем хәлендә дә имана белән аптыраталар ла», — димеш.

### II

Берәү әйтте: «Бервакытны атым чыгып киткән иде. Атымны эзләргә чыктым, бик суык көн иде. Бер өйгә барып кердем, җәмәгать белән намаз укып торалар. Араларында бер карт бар, күлмәкчән, аяклары ялангач, үзе туңган, дер-дер калтырый, әйтә: «Ярабби, бу суык үзәгемә үтте, намаз укырга кушасың, кием бирмисең. Әгәр тәмуглык булсам, хәзер керт мине тәмугка, ичмасам җылыныр идем», — диде.

## ХӘЙЛӘ ҺӘМ ТАПКЫРЛЫК.

### I

Бер үзен-үзе җыя алмаган аңгыра кызны кияүгә бирделәр. Кияү, кыз янына кергәч, күрде: кызның кулы камырлы, тырнак төпләре бар да камыр.

Кияү пакьлекне ярата торган адәм, имеш. Кызның кулын юдырырга бер хәйлә табып, ул: «Абау, эчем авырта!» — дип угалана башлады. Кыз хафаланып: «Айһай, ни дару итәек?» — дигәч, егет әйтте: «Эчем авыртканда, әнкәй кулын юып эчерсә, шифа таба торган идем», — диде. Аннан соң кыз: «Тукта, мин һәм шулай итеп караем, бәлки шифа булмасмы икән?» — дип, бер табакка су салып, кулын юды, суны егеткә бирде.

[1] Җәя эчендәге сүзләр төзүче аңлатмасы.

Егет күрде, кулында камырлар һаман бетмәгән, имеш. «Әнкәй ике кат юа торган иде», — дип, янә бер кат юдырды. Бераз торгач: «Шөкер, инде эчем авыртуы басылды, ул суыңны чыгарып түк», — диде. Кыз дәхи ул суны чыгарып түкте, хәйлә белән юдырганын аңламады.

## II

Бер егет өйләнеп кыз катына баргач, егеткә аш пешереп китерделәр. Кыз барды да иң әүвәл ашны кабып карады. Кайнар, имеш, авызы пеште. «Һай, безнең әнкәй һәркайчан ашны суытып китерә», — диде. Егет дәхи: «Мин дә кабып карыйм», — дип барды да, салкын аш капкан кебек, алып кисәктән кабып йотты, авызы пеште, тамагы пеште, бик күңелсез булды. Кыз һәм хафаланып тышка чыгып керде. Егет әйтте: «Тышта һава ничек?» — диде. Кыз әйтте: «Тыштагы һаваны сорасаң, авызы пешкән егет кебек», — диде, чөнки һава болытлы вә томанлы иде.

## III

Бервакыт хәзинәдән бер капчык алтын югалды. Казыйга[1] хәбәр бирделәр. Хәзинә йортында булган кешеләрнең барын да казый үзенә чакырды вә һәрберсенә берәр таяк бирде. Таяклар һәммәсе бер озынлыкта, бер үлчәүдә иде. Казый әйтте: «Кем дә кем угры булса, ул кешенең таягы бер бармак кадәре озын булыр», — диде. «Бар, кайтыгыз!» — дип, кайтарып җибәрде.

Капчык белән алтынны угырлаган кеше курыкты да казый биргән таякны бер бармак кадәр кисте.

Икенче көнне казый ул кешеләрнең һәммәсен үзенә чакырды, таякларын карады. Берсенең таягы бер бармак кадәрле кыска булып чыкты Мәгълүм булды, алтынны ул кеше угырлаган, имеш. Алтынны хәзинәгә тапшырып, ул угрыны сәясәт кылды[2].

---

[1] Казый — хөкем итүче.

[2] Сәясәт кылды — бу урында хөкем итте, җәза билгеләде дигән мәгънәдә.

## ТАПКЫР ХӘЛФӘ.

Бер патша үзенең углын гавам [1] балалары укый торган мәдрәсәгә бирде. Хәлфә аны укытты, кулыннан килгән чаклы тәрбияләде. Ләкин патша баласы, күпчелек укучыларга караганда, сәләтсезрәк һәм әхлак ягыннан да түбәнрәк булып чыкты.

Хәлфә бу бит патша баласы дип тормады, малайны бүтән укучыларыннан да битәр җәзалады, суктырды. Иркә малай хәлфәнең бу катылыгына түзә алмады, атасына кайтып зарланды, тәнендәге яраларын ачып күрсәтте. Патша, моны күреп, бик каты ачуланды һәм тиз генә хәлфәне үз каршына чакырып китерергә кушты.

Хәлфәне китерделәр, патша каршына керттеләр.

— Син, хәлфә, — диде патша, ачулы тавыш белән, — минем баламны хәтта гавам балаларына караганда да катырак җәзага тартасың икән. Әйт, ни сәбәптән болай итәсең?

Хәлфә аңар җавап бирде:

— Гавам балалары алар болай да тормышның ачы һәм төчесен татып үсәләр. Аларга җәфаның ни икәнен белдереп торасы юк. Патша балалары исә, киресенчә, җәфа ни нәрсә дә җәбер ни нәрсә икәнен белми үсәләр. Аннары, патша булгач, халыкка җәбер-җәфа кылуны нигә дә санамый торган булалар. Мин, шуны истә тотып, сезнең балагызга җәзаны катырак бирәм, — диде.

— Сәбәбе шул гынамы? — диде патша.

— Юк, тагын бер сәбәбе бар.

— Әйт, анысы нидән тора?

— Анысы, — диде хәлфә, — моннан гыйбарәт: гавам балалары күп вакыт, патша һәм бай балаларына чагыштырганда, үткенрәк, зирәгрәк һәм сәләтлерәк булалар. Мин сезнең балагызны өйрәтүгә күбрәк көч салам, ул исә һаман да артта калып бара.

— Алайса, мин баламны синнән укыттырмыйм, алып бүтән хәлфәгә бирәм, — диде патша.

— Анысы сезнең ихтыярыгызда, падишаһым, тик шуны онытмагыз: тәрбия бер — сәләт башка, — дип җавап бирде хәлфә.

---

[1] Гавам — халык, масса.

## ПАТША БЕЛӘН КАРТ.

Беркөн бер патша бәгъзе вәзирләре белән сәйранга чыкты, йөри торгач, бер җирдә, кешеләреннән аерылып, ялгыз калды. Үзенә бер карт очрады, һәм ул картка әйтте: «Бабай, син кайдагы?» — диде. Карт әйтте: «Мин ошбу шәһәрдәнмен». Патша әйтте: «Бу шәһәрнең хакимнәре ничек?» Карт әйтте: «Хакимнәребез бик залимнар, бик усал кешеләр», — диде. Патша әйтте: «Патша хакында ни әйтәсен?» — диде. Карт әйтте: «Мәмләкәтебездә моның кебек залим патша булганы юк иде. золымы белән мәмләкәтне корытты», — диде. Патша әйтте: «Мине таныймсың, мин кем?» — диде. Карт әйтте: «Юк, танымыйм». Патша әйтте: «Мин шәһәрнең патшасы булырмын», — диде. Карт әйтте: «Син мине таныйсынмы?» Паштa әйтте: «Юк». Карт әйтте: «Мин гажем кабиләсеннән фәлән углы фәлән мәҗнүн (җүләр), көн саен ике мәртәбә шулай җүләрләнеп, саташып йөримен», — диде.

## ХЕЗМӘТЧЕ БЕЛӘН БАЙ.

Бер кешенең бер хезмәтчесе бар иде. Аңар акча бирде, боерды: «Бар, базардан йөзем вә инҗир алып кил!» — диде. Малай базарга китте, бик озак торып кайтты. Йөзем алып кайтты. Янә икенче мәртәбә инҗир алырга китте, тәнлә кайтты. Аннан соң бае орышты, кыйнады. «Бер йомышка баргач, ике йомышны бетереп кайтыр кеше», — диде. Бервакытны бу бай сырхау булды. Баягы малайны табипка[1] җибәрде. Хезмәтче китте, табипны алып килде. Аның белән янә бер кеше ияртеп килде. Бае әйтте: «Бу кешене нигә алып килдең?» — диде. Малай әйтте: «Фәлән вакыт үзең мине кыйнадың, бер йомышка барганда, ике йомышны бетереп кил, дидең. Инде менә сиңа табип, әгәр үлсәң, менә сиңа кабер казучы, икенче мәртәбә мине йөртмә!» — диде.

## АҢГЫРАЛЫК БӘЛАСЕ.

Берәү углын сукага җибәрде, углына әйтте: «Углым, кич кайтканда, сука тимерецне яшереп кайт, угырлап китмәсеннәр», — диде. Углы барып бөтен көн сукалады,

---

[1] Табип — доктор, врач.

кич кайтканда, сука тимерен бер карама төбенә яшереп куйды.

Кайтып килгәндә, атасы берничә адәмнәр белән урамда утырып торыр. Атасына кычкырды: «Әти, сука тимерен фәлән карама төбенә яшереп калдырдым», — диде. Атасы әйтте: «И ахмак, яшергән нәрсәне шулай кычкырып әйтәләрме», — диде.

Икенче көнне сукага барса, күрде: карама төбеннән сука тимерен урлап китмешләр. Тиз үк атына атланып, атасы янына чабып кайтты. Атасы печәнлектә йоклаган иде. Атасын эзләп тапты. Атасының колагына акрын гына: «Әти, сука тимерен урлаганнар», — диде.

### ХИКӘЯТ.

Бер сабый бала, кояшлы көн бер җирдә йөргәндә, үзенең күләгәсене күреп, күләгәсе артыннан җитмәкче булды. Күләгә артыннан җитәмен дип бара. Ул барган саен, күләгә һаман алга китә. Бу баланың ачуы килеп, күләгәнең өстенә басарга теләп йөгерә башлады. Ул йөгерсә, күләгә һәм йөгерә. Бала тәмам арыды. Әйләнеп янә киткән урынына кайтып барганда артына әйләнеп караса, күләгә артыннан ияреп килә. «Һи, мин юкка йөгердем, ул миннән үзе дә калмый икән», — диде.

---

## ХИССИЯТЕ МИЛЛИЯ

(1906)

Көз җитте. Мәдрәсәләребездә укулар башлана. Уку мәдигәч тә, чын уку дип уйланмасын. Безнең бәхетсез мәдрәсәләребез һаман шул укытучы битлеген киеп, култык

астына китаплар кыстырган булып, 25 җирдән аш ашагач, абыстай янына корсагын күтәреп кайтып җитү авыр булганлыктан гына, мәдрәсәгә туктап, бераз хәл җыяр өчен генә бер чирек сәгать 5—6 кабат мендәр өстендә утырып, бераз хәл җыйгач, чыгып китә торган мөдәррисләр [1] кул астыннан һәмишә [2] чыкмагандыр.

Шәкертләребез, хөррият кояшы туып дөньяны яктырткач, борынгы истибдат [3] караңгылыгында кеше төсле булып күренгән мөдәррисләрнең кем икәнлекләрен таныдылар. Шул мөдәррисләрнең укытабыз дигән булып, шәкертләрне һич чыга алмаслык наданлык урманына кертеп адаштырганнарын аңладылар. Һәм шәкертләрнең тәхсыйле кәмаләт вә гыйлемнән [4] максутлары бер такым [5] сыра мичкәсе булган байларның этләре хөкемендә бер хайваннары булу булмаенча, азат, сәрбәст [6], һәр байдан бай, үзенә-үзе һәр падишаһдан артык падишаһ була алулары икәнлеген төшенделәр.

Инде ул шәкертләрнең шул аңлауларын вә үзләренең хөр икәнлекләрен белү хисләрен күңелләреннән кисеп ташламаган тәкъдирдә, алар һаман бөтен көчләре, тешләре вә тырнаклары илә үзләрен шул залим мөдәррисләрнең вә надан зур корсаклы байларның кулларыннан коткарырга тырышачаклардыр. Шәкертләр, бу көннән алып, үзләренең милләт эчендә иң кадерле, иң дәрәҗәле бер затлар икәнлекләрен аңлап вә аңлатып, үзләренең иң түбән теләнчедән дә түбән бер мескеннәр түгеллекләрен күрсәтәчәкләрдер. Инде шәкертләр бер саран байның күз карашларын тәгъкыйп итеп [7], безгә ничек карар икән, мәрхәмәтле карар микән, мәрхәмәтсез карар микән, алафранка [8] киенгәнемне күрсә, ашка чакырыр микән, дип калтырап тормаячаклардыр.

— Алар, бу хурлыкларны күргәнче, нинди кәсеп итсәләр дә, үзләрен үзләре кул көчләре берлә туйдырачаклардыр.

---

[1] Мөдәррисләр — дәрес бирүчеләр (муллалар).
[2] Һәмишә — һаман.
[3] Истибдат — реакция, искелек, деспотизм.
[4] Тәхсыйле кәмаләт вә гыйлемнән — белем алу һәм өйрәнү мәгънәсендә.
[5] Бер такым — берничә.
[6] Сәрбәст — ирекле.
[7] Тәгъкыйп итеп — күзәтеп.
[8] Алафранка — французча (европача). Биредә шәкертләрнең яңачарак киенүләре турында сүз бара.

Миллэт образованный кешелэргэ һэм халык файдасын һэртөрле үзенең шэхси мэнафигыннан [1] вэ корсак файдаларыннан өстэ тота торган, миллэт файдасын күз өстендэге каш дэрэҗэсендэ газиз тота торган миллэт арсланнарына мохтаҗ. Миллэт аталарга, аналарга, мөгаллимнэргэ, мөгаллимэлэргэ [2], мөрэббилэргэ вэ мөрэббиялэргэ [3], чын мөхэррирлек табигатьлэренэ вэ салахиятлэренэ [4] мохтаҗ. Безнең миллэт тэ, башка миллэтлэрдэге кеби, хамисез [5], мэлҗээсез [6], фэкыйрь вэ эшче халыкның файдаларына тырышучы, биш фэкыйрь кешене бер бай итенэ алмаштырыр вакытлар үткэнлеген аңлаучы вэ аңлатучы егетлэргэ мохтаҗ. Безнең миллэт тэ Пушкиннарга, граф Лев Толстойларга, Лермонтовларга мохтаҗ. Кыскасы гына, безнең миллэт тэ башка миллэтлэрнең тэрэкъкыйлэренэ [7] сэбэп булган чын мөхэррирлэргэ, рэссамнарга [8], яңа-яңа милли шагыйрьлэргэ, музыкантларга вэ гайрелэргэ [9] мохтаҗ.

Бу эйтелгэннэр булмаганда, безнең тормышыбыз күңелсез, үлек чыккан өй төсле моңлы, тынсыз, тавышсыз, рэхэтсез булачактыр.

Болардан башка безнең гомеребез бер дэ бэйрэмсез, гомерлек мэшгулият, яки бер дэ җэйге кояшсыз мэңгелек көз көне төсле үтэчэктер.

Яшьлэргэ, баягы хэзрэтлэрнең мендэр өстендэ ял иткэннэренэ генэ канэгатьлэнмэенчэ, уку кирэк. Бу аларның иң мөкатдэс [10], иң беренче вазифаларыдыр [11].

Бу безнең һэртөрле чалмалы бурлаклар тырнагыннан азат булуыбызга вэ бюрократия золымыннан, башка миллэтлэр илэ берлектэ, безнең дэ котылуыбызга иң беренче вэ иң тугры юлдыр. Укымак — дөреснең ялганны, яктылыкның караңгыны, турының кэкрене, сафлыкның бозыклыкны җиңүлэренэ иң үткен, иң кирэкле коралдыр.

---

[1] Мэнафигыннан — файдаларыннан.
[2] Мөгаллимнэргэ, мөгаллимэлэргэ — ир укытучыларга, хатын-кыз укытучыларга.
[3] Мөрэббилэргэ вэ мөрэббиялэргэ — тэрбияче ир һэм тэрбияче хатын-кызларга.
[4] Салахиятлэренэ — сэлэтлэренэ.
[5] Хамисез — яклаучысы булмаган.
[6] Мэлҗээсез — сыена торган урыны булмаган.
[7] Тэрэкъкыйлэренэ — алга китүлэренэ.
[8] Рэссамнарга — художникларга.
[9] Вэ гайрелэргэ — һэм башкаларга.
[10] Мөкатдэс — изге.
[11] Вазифаларыдыр — бурычларыдыр.

Укымак — фикерләрне җирдән күккә җибәрмәк. Укымак — үз янында булып торган нәрсәләрдән бигрәк, фикерләрне булачакларга сузмак. Укымак — үткәннәрдән кичеп, киләчәкләр — истикъбальләр [1] тугрысында пәйгамбәрлек итмәк. Укымак — хәзерге көннәрне киләсе көннәр өчен, бу көнге мәсьәләләрне киләчәктәге мәсьәләләрне чишү угрында ташламак димәктер. Укымак — бүгенге дуслардан киләчәктәге кара көннәр өчен аерылмак димәктер. Укымак — үзеңне һәрнәрсәне белергә вә һәр максутка ирешергә вә бөтен дөньяга солтан булырга лаек дип танымактыр. Укымак — «иҗтиһад монкариз» [2] кеби сүзләрдән ха-ха-ха илә көлеп, гакыл пычагын гыйлем вә мәгърифәт кайрагына чынлап кайрамак дигән сүздер. Укымак — утыз ел мәдрәсәдә ятып, бер татар баеның эштән чыккан кызы илә бер аулак бүлмәгә кереп яту, соңра шул байның бер асрау малае булып тору дигән сүз түгелдер.

Укымак ләфзы [3] астында моның кеби хисапсыз мәгънәләр чыкса да, барчасы үз халкыбызга хезмәт итмәк дигән сүзгә кайтадыр. Укымак — халыкның бәлешен ашап, каның эчеп, үзеңне симертеп, ел саен бер бай кызы үтереп яки аерып, хайванлык итеп яту дигән сүз түгелдер.

Беләмсен ки, безнең шәкертләребез бу мәгънәләрнең барчасын аңлаганнардыр, алар шуңар күрә үзләрен теләнче ясап чыгара торган, тугрысын әйткәндә, теләнче фабрикасы булган мәдрәсәләрене ләгънәт укып чыгып киткәннәрдер.

Шәкертләребезнең бу хәрәкәтеннән милләт әллә нинди зур өмитләр вә сәгадәтләр көтсә дә урынлыдыр; яшьләребезне кайда укытырга вә ничек укытырга икәнен белсәк, милләт өчен җаннарын корбан итүчеләр вә үзләренең бил бәйләп керешкән юлларыннан, әллә нинди куркынычлар, әллә нинди хәвеф-хәтәрләр очраса да кайтмый торганнар һәм шулай булырга салахиятлеләр дә, анчак, яшьләребездер.

Без шәкертләргә, үзебезгә кирәк кадәре динебезне вә әдәбиятыбызны аңлагач, вакыт кичермичә, хөкүмәтнең реальныйларына вә гимназия казаннарына кереп, пешеп, кеше булып чыгарга кирәк. Русларның үз балалары

[1] Истикъбальләр — киләчәкләр.
[2] Иҗтиһад монкариз — дин һәм тормыш мәсьәләләре турында фикер йөртү заманы үткән дип карау.
[3] Ләфзы — сүзе.

кайсы мәктәпләрдә укыса, бездә дә шуларның итәкләренә ябышып керергә тырышырга тиешләр.

Хәзер дә милләткә чынлап риясыз, нифаксыз [1] хезмәт итүчеләр шул мин теләгән юл илә укыган яшьләребездер.

Без яшьләребезне Бохарага җибәрсәк — ишәк, Истамбулга җибәрсәк — полицейский вә шпион булып кайтачаклары моңарчы кайтканнары илә сабит вә мөдәлләлдер [2].

Әле Мәкәрҗә базарында да җыелышлар, шураи өммәтләр [3] булып үтте. Мосадәмәи әфкярдән барикаи хакыйкать зоһур итәр [4] дигән шикелле, шул җыелышларыннан берәр төрле файда чыгып китсә, шаять, без шәкертләргә дә гомеребездә, элек дәфга [5] уларак, чын гыйлем илә сәламләшеп, гыйлемнең алдына тез чүгеп, кулларын үбеп, моңарчы гыйлем дип, гыйлемгә табан-табанга зыйд вә кире [6] нәрсәләр берлән баш катырып йөргәнебез өчен гафу үтенер көннәр җитәр; тырышыгыз, карендәшләр, шәкертләр, тырышыгыз, муллаларның мендәр өстендә корсак шиңдереп утыруларына гына канәгать итмәгез, бөтен өмитебез, бөтен риҗа вә илтимасыбыз [7] анчак сезгә гаиттер!

## МӘКАЛӘИ МАХСУСА

**(1912)**

### III

Уфага җиттем. Тау башында тәртипсез таралып утырган. Извозчикка утырдым. Ләкин бу инде Самараныкы түгел иде. Арбасы шундый иске, шундый каты иде ки, эчәкләрем такта арбага буш салган дилбегә кеби үрле-

---

[1] Р и я с ы з, н и ф а к с ы з — ялагайлыктан, икейөзлелектән башка.

[2] С а б и т в ә м ө д ә л л ә л д е р — раслаиган, исбат ителгән.

[3] Ш у р а и ө м м ә т л ә р — бер диндәге кешеләрнең җыелышлары (бу урында 1906 елдагы мөселманнар съезды күздә тотыла).

[4] М о с а д ә м ә и ә ф к я р д ә н б а р и к а и х а к ы й к а т ь з о һ у р и т ә р — фикерләр бәрелешүеннән хакыйкать яшеннәре туар.

[5] Э л е к д ә ф г а — беренче тапкыр.

[6] З ы й д в ә к и р е — каршы һәм кире.

[7] Р и җ а в ә и л т и м а с ы б ы з — үтенү, соравыбыз.

кырлы сикерэ иде. Таудан акрынлап менэсең, юлның этрафында җэһэннэм кеби тирэн чокырлар — хисабы юк. Җэһэннэмнең тирэсенэ саклык өчен тезгэн баганаларның арасы бик сирэк булып, арба янтайса, мөкиббэн галэ вэҗһиһи[1] җэһэннэмгэ төшү бик мөмкин иде.

Уфага кергэндэ бер дэ шэһэргэ кергэн кебек булмый. Эллэ нинди ачык, тишек вэ рэтсез һэм пустынный урамнар белэн барасың. Эч поша. Кая соң моның шэһэрлеге! дип сукранганда, көчкэ беркадэр яхшырак урамнарга кердек. Шулай барганда «Сабах» көтепханэсенең[2] ак вывескасы күренде. Тугры анда туктадым.

«Сабах» ка килүдэн максудым, Самарадагы кеби, бер «Бристоль»гэ барып элэкмэскэ, ягъни нинди номерлар ничек булачагын сорашу иде. Лэкин, күрдем ки, магазинга тоташ шундый киң вэ яхшы бер квартира бар, монда мин түгел, миңа тагы 19 кеше кушсаң да сыярлык иде. Җитмэсэ аның асты кухня булып, һэрвакыт астан җылы бэргэнлеге беленде. Менэ рэхэт! Менэ икенче лэүкэ. Монда китап төялеп килгэн гайре мөтэнаһи[3] ящиклардан кровать ясау вафля пешерү шикелле тиз. Аста ящик булса да, өстенэ йомшак вэ матур нэрсэлэр каплагач, ярый ул. Өстеңдэ эйбэт кием булгач, синең бэрэңге ашаганыңны кем белэ? Урамга чыксаң, мыекны кашыктагы май белэн майлап була. Дөнья яратылганнан бирле ялганнар күбесенчэ тотылмый калган...

...Мин фэкыйрь дэ татар вэ исламга гаит[4] эшлэрдэ «чебен тимэс чер итэр» бер кеше булганымнан, «Япониядэ мөселман идүче голэма нэрэдэ?»[5] сэрлэүхэле[6] бер шигырь язган идем.

Квартира, гомумэн, күңелле. Кеше күп килэ. Эч пошарлык түгел. Монда һэр көн мөхэддисе кэбир[7] Эхмэт Фаиз Даутов белэн күрешэбез. Ул скрипкада маташтыра, элегэ яхшы уйный алмый. Лэкин җырласа, мин андый җырны гомеремэ тыңлар идем. Аның гади сөйлэшүдэ дэ металлический вэ музыкальный тавышы җырлау заманында бөтен көчен вэ голвиятен изһар итэ[8]. Мин

---

[1] Мөкиббэн галэ вэҗһиһи — йөзтүбэн.
[2] «Сабах» көтепханэсе — китап кибетенең исеме.
[3] Гайре мөтэнаһи — чиксез күп.
[4] Гаит — караган.
[5] Голэма нэрэдэ — галимнэр кайда?
[6] Сэрлэүхэле — исемендэге, исемле.
[7] Мөхэддисе кэбир — пэйгамбэр сүзлэрен күп белүче
[8] Голвиятен изһар итэ — бөеклеген күрсэтэ

Латыповны ишеткәнем юк, ләкин Камил буш бугаз кебиләрне бу җирдә телгә алырга да хурланам. Петербург профессорлары хәзер башкорт халкының бик тиздән монкариз булачагына [1] иман иткәннәр. Башкортларның гадәт вә әхлакларын язу һәм кием вә зиннәтләрен музей өчен тикшереп ятмакталар икән. Әгәр Фаиз әфәнде кеби чын башкорт рухы вә башкорт моңы белән җырланган җырлар да граммофоннарга алынып калса, моның башкорт инкыйразыннан [2] соң азмы әһәмияте булыр иде?! Ләкин милләтемез дингезенең энҗеләре төптә ятып, «ул-бу»лары гына өскә калка шул.

Дикъкать итәсезме? Хәзер граммофонга җырлау фахишәләр вә әнваг [3] эшсез, ашсызлар кәсебе булды. Казанның «Кәҗә Маһи», «Подвал Фатыйма», «Этле Хөсни», «Җиңгәчи кызлары»на кадәр, төрле шәһәрләрдә граммофонга җырлап, милләтнең сәмгын [4] мәсхәрә итеп бетерделәр. Фахиш тавыш, фахиш рух, фахиш көй! Фахиш мәгънә! Менә шулар безнең фахшиятсез, пакь мөселман түрләренә кереп утыралар. Түрдә утырып граммофоннар сүгенәләр. Мин Казанда, Астраханьда әллә ничә граммофоннан шуны уйнатучы гаилә эфрады [5] өчен кызарып утырдым. Алар минем кәефемне ачарга граммофон боралар иде. Мин исә чыраемны сытып утыра идем. Чөнки алар шикәр дип үзләре белмичә ачуташ каптыралар иде.

## IV

Уфаның мәгъмурияты [6] ягы Казаннан күп начар булса да, табигать ягы күп шәһәрләрдән өстен. Әүвәл үк тау башында, димәк, җәй көне дә, кыш көне дә һава яхшы. Җырларымызда шулкадәр күп җырланган Агыйдел буенда. Шәһәр эчендә йортларга караганда агачлар күп диярлек. Моның җәй көнеге әһәмияте! Өстәь караштa Уфаның халкы да айнык вә саф күренә. Чөнки бу шәһәрдә чат саен халык саулыгын химая итә [7] торган сөт ки-

[1] Монкариз булачагына — бетәчәгенә.
[2] Инкыйразыннан — бетүеннән.
[3] Әнваг — төрле.
[4] Сәмгын — тыңлау тойгысын.
[5] Гаилә эфрады — семья членнары.
[6] Мәгъмурият — төзеклек.
[7] Химая итә — саклый.

бетләре. Һәммәсендә халык. Пивнойлар сирәк. Бу шәһәр «Ай-һай Казанның каласы, аза ишан баласы» түгел. Сөт сатучылар, мендәргә утырган мулла кеби, үзләре хезмәт итмиләр. Сөт эчүчеләр үзләре буфеттан сөт алып килә. Чөнки... сөтче сиңа сәламәтлек бирә, алар нишләп үзләре хезмәт итсеннәр... Сау буласың килсә, әнә сөтне үзең барып ал! Монда трактир официантлары кеби рия, нифак [1] вә посетительгә ярарга тырышып кылану күренми.

Фәлсәфәгә кердем... язам, язам, — кая көлкесе?..

Урман, урман, — кая төлкесе?!

## V

Әйе, урманның да бөтен җирендә төлке булмый, мәкаләнең дә һәр сәтырында [2] көлке булмый. Актар агач араларын, бардыр төлкесе, укып чык бөтен караларым, бардыр көлкесе.

Мәҗит әфәнде Гафури белән күрештек. Ул миңа карагында да юашланган вә дөнья тарафыннан басылган кеби күренде. Аның белән безнең мосахәбәмез [3] күп вакыт күзләр аркылы гына кылына иде. Читтән безне караган кеше икемезне әле генә хисапсыз каты шаярып, соңра аналары кыйнап, бер минут элек кенә елаудан туктаган балаларга охшатыр иде.

Нишлик соң? Шаярыр идек, әле генә язмыш ханым кыйнаган; елар идек, әле күздә яшемез дә кипкән.

Россиядә хәзер уйнаган җилләр вә Россия һавасы безнең бөтен коллегаларымызны шул халәте рухиягә китергән...

Әйе, әле күздә яшемез дә кипкән. Киләчәктәге шатлык яки ерак, яки юк.

Уфада шактый заман торсам да, аның эчен вә этрафын карап йөри алмадым. Мәҗит белән йөрергә чыксам да, ярты юлда хәл беткәч, өйгә борыла идек. Монда трамвай юк. Извозчикта эч кенә авырта, эч авырттырмый торганына утырсаң, кесә авырта иде...

Әлкыйсса [4], мәзкүр [5] нәрсәне күрсәтмәгәннәр.

Хәзергә җитәр әле.

---

[1] Нифак — бозык.
[2] Сәтырында — юлында.
[3] Мосахәбәмез — сөйләшүебез, әңгәмәбез.
[4] Әлкыйсса — кыскасы.
[5] Мәзкүр — әлеге.

## VI

Өстән генә электереп киту тарзын алган [1]... мондый сәяхәтнамә өчен Уфада артык нәрсә күрмәдем, бугай.

Хәер, шәһәр бакчасында өстенә җөббә, башка зәңгәр фәс, күзгә күзлек, аякка «ботинка», авызына кош каналы төшәрлек дәрәҗәдә, борынын күтәреп барган бер мәгърур шәкертне туктатып, юри «вәкар [2] вә мәһабәтен» бозар өчен «Син курай уйный беләсеңме?» — дип сорыйсым килде. Мин үзем, гомумән, шундый «кәмитле» мәһабәтлекне бозудан ләззәт табам. Аннан соң без беләбез ки, татар шәкертен кеше ясар өчен иң элек аның «вәкарен» бозарга кирәк.

Бу, өй салганда иң элек нигездән башлау, сүткәндә түбәдән тотыну кеби кагыйдә инде.

Андый «вәкар», яшьлектә җимерелмәсә, бәгъзан, мөхәррир булып гомер итеп, неграмотный үләчәк «зате галилэрдә» [3] дә кала. Мисал эзләсәгез, күктән йолдыз эзләгән кеби генә булып, аны табуда зәхмәт чикмәссез.

Әле апрельнең әүвәлге яртысы гына җитә. Минем өчен көннәр әкрен кичәләр. Апрельнең әүвәл ягыннан, «әүвәл коръан»нан чыга алмый йөдәгән малай кеби, мин дә үтә алмыйм. Малай, хәлфәсе сизмәгәндә, сабагын «сикерткән» кеби, мин дә күп йоклап карыйм. Ләкин максады аслый [4] булган кымыз сезоны җитми. Уфада кымыз юк.

Дөрес, мин кымызны Уфада да, әтрафында да эчәчәк түгел. Мин аның өчен Троицкига барырга Казаннан ук карар биреп чыккан вә йөзләп баш бия саудыра торган бер Троицк кешесенә барасы, кымызны савылган урында чатыр тегеп торып эчәсе кеше. Чөнки Уфа әтрафын европалылар басып, биттабгы [5] андагы кымыз искусственный (җагли) лаганлыгыннан хәбәрем бар иде. Ләкин Уфада да кымыз булмаганлыгыннан, Троицк «кусагасылары» [6] ның да «бия байламаганлыгын» истидлаль итә идем [7].

---

[1] Тарзын алган — төсен, формасын алган.

[2] Вәкар — тәкәббер.

[3] Зате галиләрдә — югары затларда.

[4] Максады аслый — төп теләк.

[5] Биттабгы — табигый.

[6] Кусагасылары — биредә Тукай кымыз эчетүче казахлар турында сөйли.

[7] Истидлаль итә идем — уйлап белдем.

Шулай, ни ары, ни бире булып торганда, кесәмдәге, Петербургка мине чакырып язган, бер хат исемә төште. Бу хат инде беренче түгел, берничәнче иде.

Буш та түгел, җитди иде. Ләкин җитди булса да, мин Петербургка баруны көзгә, кымыз эчеп хәлләнгән чакка китермәкче идем. Юк инде, Петербургка хәзер барам. Кымыз да булмагач, Уфада нәрсәгә ятыйм? Җитмәсә аның «авыллыгы», тынлыгы, җансызлыгы минем әле хасил[1] булмактагы европалылыгымны, культурный шәһәр кешесслегемне, шау-шу яратучылыгымны, галәбәлек[2], көрәш сөючелегемне үчекләгән кеби булды. Китәм Петербургка! Кымызга кадәр торам. Телеграмма, ответ. Киттем.

---

[1] Хасил — барлыкка килү.
[2] Галәбәлек — өстенлек, җиңү.

# ЯРЛЫЛАР ЯКИ ӨЙДӘШ ХАТЫН

## (1909)

### I

Мин тора торган шәһәрнең уртасында базар булып, ул базарның да уртасында бер җирдә һәрвакытта эш эзләп, эш көтеп тора торган ярлылар була торган иде. Кем нинди эш куша, нинди хезмәт тугры килә, алар шуны дүрт күз илә көтеп кенә торалар иде. Бер кешегә утын ярдыру, кар көрәтү кеби кара эшләрне эшләргә кеше кирәк булса, шул эш көтеп тора торган ярлылар янына килеп, аларның берсене алып китә иде.

Монда эш көтеп тора торган ярлыларның куллрыннан килә торган эш утын яру, кар көрәү, пычрак чүплэрне тазарту кеби, бик агыр кара эшләр генә булып, кораллары да кирәк, балта кеби нәрсәләр иде. Болар шул һөнәр вә шул кораллары илә кул көчләре аркасында тамакларын туйдыралар иде. Бу ярлылар, солы катыш үскән богдай кеби, татар илән руслары катыш торалар иде. Боларның һәр көнге гадәтләре иртә ук торып, шул җиргә килеп җыелып, эш көтеп тору, эш булса, эшләп кайту, эш булмаса, кайгылы сурәттә кайту иде.

Менә бу көндә алар гадәтләре буенча иртә намаз вакытында ук бу җиргә ризык эзләп килеп тулганнар иде. Бу көн кышның иң салкын көне булып, кара халык тогъбиренчә әйткән вакытта, тирә-як җиргә төшмәслек чатлама суык иде. Кояш яңа гына чыгып, тирә-ягы зур алка илә әйләндереп алынган иде. Кояшның бу йлә киртәләнеп зур алка (даирә) эчендә калуы бик салкын вакытларда гына булганга күрә, кояшка караганда кояш үзе бер салкын боз табы кеби күренә иде.

Базарга утын, печән сатарга килә торган авыл кешеләренең йөгерә-йөгерә атлары вә чаналары яныннан килүләре, дагасыз атларның, тоякларына ябышып каткан бозлары сәбәпле, тарта алмый әрле-бирле селкенүләре, бу атлар асылда кара туры булып та, тирләп чыккан парлары өсләренә бәс булып ябышкач, ап-ак булып күренүләре, борыннарына сыер имчәге кеби бозларның катулары көннең рәхимсез салкын икәнене күрсәтә иде. Морҗалардан чыгып бик югары күтәрел-

гән, салкынлыктан зур тирәкләр шәклен алган төтеннәр ниһаятьсез күп булып, читтән караганда кара урман кеби булып күренә, һәр кешенең өйдә генә утырганыны искә төшерә иде. Урамда йөрүчеләр бик аз булып, аларның да ихтыярсыз йөгерә-йөгерә барулары бик зарур йомыш илә чыкканлыкларыны белдерә иде. Бу йөрүчеләр тиз-тиз колакларын, битләрен ышкыйлар, бара торган җирләренә барып җиту илә, тишегенә качып кереп киткән тычкан кеби, тиз генә кереп югалалар иде.

Менә шулай салкын көндә тегс эш эзләп чыгучы ярлылар үзләренең мәҗмәгелфокара[1] булган урыннарына әллә кайчан килеп тулганнар, бик ашыгычлык илә эш көтәләр иде. Болар эш көтә-көтә аптырагач, салкынлыкка чыдый алмагач, ике кулларын бер-берсенә китереп җиңнәре эченә тыгып куйганнар, кулларында бияләйләре булганы өшемәскә тырышып ике кулны бер-берсенә шап-шоп иттереп сугалар, әрле-бирле йөгерәләр, берберсе илә күрешеп алышып та киткән булалар, «ә, корт чага, корт чага» дип, тиз-тиз колак һәм борыннарын ышкыйлар иде. Никчаклы салкынга бирешмәскә, чын куәтләре илә мокавәмәт итәргә[2] тырышсалар да, салкынлык боларга галип килә[3], боларны калтырата, иң нечкә җирләренә чаклы барып, без кеби чәнчеп-чәнчеп ала иде. Өйләрендә тычкан туярлык та ризыклары булмаган бу ярлылар, эш кушучылар чыкмас микән дип, өмит итеп, бу көнгә җитәрлек ризык алып кайтып балачагаларыны туйдыру кирәк идекене исләренә төшереп, шул 25—30 дәрәҗә салкында торалар иде. Кайда булса да бер үлем диган, күз керфекләренә кар ябышып, сакал-мыекларына боз катып, калтырашып торган бу ярлылар ничек булса да үләр дәрәҗәгә килгәнче эш көттеләр. Ни чаклы тилмереп көтсәләр дә, бик аз гынасына эш табу насыйп булды.

Эш тапканнары шатлыкларыннан сикерә-сикерә китәләр, монда калганнары аңа кызыгып, «безгә дә шулай эш табылса, ничек рәхәт булыр иде» диган төсле, калалар иде. Калганнары никадәр зур өмет илә эш көтсәләр дә, бер дә эш табылмады. Киемнәре берәр кат чикмән

[1] Мәҗмәгелфокара — ярлылар җыела торган урын.
[2] Мокавәмәт итәргә — каршы торырга.
[3] Галип килә — җиңә.

илә иске генә бишмәттән гыйбарәт булган бу ярлылар көтүнең актык дәрәҗәсенә җитеп, камил өмет өзгәч, өйдә аз гына ашарларына булганнары кайтып китә башладылар. Бу урында бик аз гына ярлылар торып калды. Монда торып калганнарның өйләрендә бер сынык булсын икмәк, бер чеметем чәй булмаганнарыдыр. Боларның максудларының гаясе[1] шушы салкында эш табып, 20—30 тиен акча алып кайтмак, шуның илә бу көн киченмәктер. Бу җирдә торып калганнарының эчендә кыска гына чикмән кигән, биленә бер җеп берлә генә бәйләгән, төрле чүпрәкләрне, иске тулаларны җыеп, аягына урап чабата кигән, чикмәне кыскарак булу сәбәпле, тезе тугрысында кызыл штаны күренеп торган, күрәгәне култыгы астына кыстырган дер-дер калтырап торучы Шәриф дигән кеше дә бар иде.

Безем ярлылар арасыннан алып, хәлене язачак ярлы зат ошбу Шәриф агай булганга күрә, моны онытырга тиеш түгел. Шуның өчен мин аны укучыларга артыграк тәгъриф итеп китмәкче буламын.

Шәриф бу шәһәргә ерак түгел бер авылда туган, бала вакытында уку-фәлән күрмәгән, ятим калып, шул вакыттан бирле рәхәт күрмәй фәкыйрьлектә үскән, гомере буенча шуның кебек кара хезмәтләр илә генә тамагыны туйдырып көн үткәргән, ләззәт-рәхәтнең ни икәнене белмәгән бәхетсез бер кешедер. Менә монда торган вакытта да ике күзеннән ихтыярсыз үзе белмәй торган күз яшьләре ага, чуалып беткән сакалына тама да боз булып ката, салкынлыкка чыдый алмый калтырана, әрле-бирле йөгергәләп, әллә ниләр уйлап эш көтә иде. Аның өендәге, эти нәрсә алып кайтыр икән, дип көтеп утыра торган балалары исенә төшә, ничек булса да бу көн ашарлык нәрсә алып кайтасы килә, шулай мөҗәссәм[2] ярлы булып эш көтеп тора иде.

Шәрифнең ярлы иптәшләре, салкынга чыдый алмый, берәм-берәм кайта башладылар. Шәриф тә бик кайтыр, бу салкында бер минут та тормас иде, ләкин өйдә бер дә ашарга булмагач, анда хатын, бала-чагалары ач көенчә көтеп утыргач, ничек булса да берәр эш табып кайтуны өмет итә иде.

---

[1] Гаясе — чиге.

[2] Мөҗәссәм — җисемләнгән (бу урында «нәкъ ясап куйган ярлы» мәгънәсендәрәк).

Иптәшләре таралып беткәч, Шәриф бик шатланып, «инде үзем генә калдым, шаять берәр эш тугры килер», дип торган чакта, бер маржа Шәрифнең янына килеп, «әйдә, бу әйберләрне күтәреп алып бар әле», дигәч тә Шәриф, аллага шөкерләр кылып, марҗаның әйберләрене күтәреп алып китте.

Юлда барган чакта ләззәтле хыял илә, «бу маржа ун тиен бирер микән? Әгәр дә ун тиен бирсә, ике кадак икмәк һәм, үземнең янымдагы бер тиенне кушып, өч мыскал чәй алып кайтыр идем», дип уйлый вә рәхәтләнә иде. Ул шулай унбер тиен акчасыны нинди урында тотарга кирәк икәнне уйлап бара торгач, марҗаның тора торган өенә барып та життеләр. Өйгә кереп, әйберләрне идәнгә куйгач, теге маржа чишенеп, кесәсеннән унике тиен акча алып, Шәрифкә тоттырды. Менә шатлык! Һич уйламаганда, унике тиен акча бирде...

Шәриф шатлануыннан нишләргә белмәй өйгә карап йөгерде. Кайтып барганда, үзләренә якын лавкадан ике кадак икмәк илә бер кап шырпы, өч мыскал чәй алып кайтты. Тора торган кечкенә фатиры шәһәрнең читендә булса да, бик тиз кайтып житте, өенә барып кергән вакытта гүя хатын, балаларына мактанган кебек: «Менә атагыз малны шулай таба ул, чыкты исә, ала да килә», дигән төсле, култыгындагы әйберләрне сәке өстенә бушатып ташлады. Үзе бик зур бер бурычтан котылган, өстән тау кеби авырлыкны алып ташлаган кеше кеби, чикмәнне салып көлмәкчән генә калды.

Шәрифнең хатыны Бәдриҗамал исемле булса да, ярлы булганга күрә, Бәдри яки Бәдрәш кенә дип йөртә торганнар иде.

Бәдри ул Шәрифкә итагатьле генә һәм аның тормышына өйрәнгән, Шәрифне эшлекле дип игътикать итә[1] торган иде. Озын гына буйлы, ач яңаклы, күзләре эчкә баткан, мәэюс кенә бер сыйфатта иде.

Өстенә кигән күлмәгенең ике җиңе ак, билдән югары тарафы кызыл, түбән тарафы саргылт, башына ураган, былтыр урак вакытында алган яулыгы кып-кызыл булганга күрә, ала киемле дип әйтерлек иде.

[1] Игътикать итә — ышана.

Боларның ике баласы булып, берсенең исеме Гөлҗиһан булып, җиде яшендә, икенчесе ир бала булып, Ходайбирде исемендә, дүрт яшендә иде.

Бу вакытта Гөлҗиһанның күлмәге таза гына булып, итәге генә ертылган, саче тарак юкка күрә таралмаган, чуалып беткән көенчә, ике кулы илә тиз-тиз башын кашып, яланаяк көенчә, мич алдында тора иде.

Ходайбирденең штаны юк, кап-кара күлмәк кигән, изү бавы ычкынган, ике җиңене салындырып, кулларыны эчкә тыгып, башыны иеп, бөгәрләнеп утырган, ике танау тишегеннән маңкасы кап-кара булып салынып төшкән, инде агызына керә дип куркып торганда гына кире тартып ала иде. Башының сачене утмәс пәке берлә алганга күрә — тигезсез, аның өстенә өч-дүрт урында кутыр булып канаганга күрә, кәгазь ябыштырган иде. Аталарының бу нәрсәләрне алып кайтканыны күргәч тә, ачлыктан агарган йөзләрендә шатлык, кугәреп эчкә баткан күзләрендә хәят эсәре заһир булып, йөгереп, аталары алып кайткан нәрсәләре янына барып, тотып-тотып карадылар.

Бәдри: — Сабыр итеп торыгыз! — дип икмәкне алып куйды да, үзе самоварны алып, тиз генә кагып, су салып, мич алдына утыртты. Яңа алып кайткан шырпыны ачып чыра яндырып, калай самоварның эченә салып җибәрде. Шул вакытта инде Шәриф: «Бу шырпыны саклабрак тот. Бик тиз бетә, беләсең бит, бу заманда акча табуы бик уңай эш түгел, әле дә тырышлык аркасында гына тамаклык акча таба алам», — дип, үзе генә ашарга табучы икәнне белдереп куйды.

Бәдри: — Әле дә алла ярдәм бирә әле, бу көн бик суык булганга күрә, бер дә эш булмас, ач торсак та өйдә генә ятмый, юкка чыгып китте, дип кайгырып тора идем.

Шәриф: — Суык дип, ач ятып булмый шул.

Бәдри: — Ничек бик тиз кайттың? Ни эш эшләдең?

Шәриф (эш таба торган кешеләр тавышы илә): — Бу көн кар-фәлән яумаган, кар көрәтүче булмады. Көн салкын булганга, утын ярдырырга эзләүче дә күренмәде. Менә шулай аптырап торганда гына, алланың рәхмәте илә, бер маржа, өмет итмәгән җирдән, килеп чыкты. Шуның әйберләрене күтәрешеп алып барган идем. Уп

тиен бирсә ярар инде дип торганда, уникс тиен көмеш акча чыгарды да бирде. Бу әйберләрне шул акчага алып кайттым.

Шул вакыт Ходайбирде мич башыннан төшеп, ялан-аяк көенчә, йөгереп тышка чыгып китте. Ул кире кергәч, Шәриф: «Нигә өйне суытып йөрисең? Куян аягы ашадыңмы әллә?» дип сорады да, Бәдригә карап: «Тизрәк самоварны кайнат әле, чәй эчеп, дәхи бер чыгып карарга кирәк, берәр эш табылмасмы, бер бәхет ачылса, ачыла торган ул, өйдә яту берлә әллә ни булмас», диде.

Бәдри: — Бу көн бик суык бит, инде чыкмасаң да ярар.

Шәриф: — Чыкмый булмас, чыгып карарга кирәк, бот күтәреп көтеп, буш ятсаң, ашарга китереп бирмәсләр. Менә әле көн салкын дип, иртә берлән чыкмаган булсам, бу көн ни ашар идек?

Бәдри самовар янына барып, өреп-өреп: «Таш кергән самовар, әле булса кайнап чыкмый, ничаклы күмер кирәк», дип чиертеп, алай-болай итеп утыра торгач, самовар калтырый башлады. Димәк, кайнады. Әлеге өч мыскал чәйне ертып, кечкенә кыршаулы кара чәйнеккә чәй салып, утыртып куйды. Кечкенә генә ертык ашъяулыкны җәеп, пар ярым чынаякны китереп куйды.

Менә көткән рәхәтләре булган чәйне эчәргә утырдылар.

Баягы ике кадак арыш икмәгене Бәдри кулына алып, ике зур гына телем кисеп, Шәриф алдына, бер телемне үз алдына куйды. Бу вакытта барчасының күзе шул ике кадак икмәктә иде. Дүртенче телемне кисте дә уртага бүлеп, берсенс Гөлҗиһанга, яртысын Ходайбирдегә бирде. Калганын кулында тотып торган чакта, чак-чак чыдап торган Шәриф: «Җитәр инде, телмә! Кич ашап ятарлык калсын, әллә бу көн эш табып була, әллә юк, бар чакта бүредәй, юк чакта шүредәй торырга ярамас, азрак кысынкырак ашарга кирәк», — диде. Ходайбирде икмәкне кулына алгач, бик шатланып ашарга да, ашамаска да белмәй, әрле-бирле әйләндереп карап, менә минеке күбрәк дигән төсле Гөлҗиһанга күрсәтә, күзе янына гына алып барып, икмәкне тезләгән кеби кырыннан гына Гөлҗиһанга карый иде.

Бәдри, бер пар чынаякка чәй ясап, Шәриф алдына куйды, икенче чынаяк астына чәй ясап, үзе алып эчә башлады.

Әллә кайдан алып кайткан бер кисәк шикәре исенә төшеп, куйган җиреннән алып, икегә бүлеп, яртысыны Шәрифкә бирде. Калган яртысыны дәхи икегә бүлеп, берсене Гөлҗиһанга, берсене Ходайбирдегә бирде. Кечкенә шикәрне кулына элэктергәч, Ходайбирде бигрәк шатланды. Ни эшләргә белмәй аптырап бераз торгач, үзенә чәй эчәргә нәүбәт җиткәнче бер кәгазь алып, төреп куйды да Бәдригә карап:

«Әни, мин чәйне бу шикәр белән эчәрмен, яме!» дип тәэкид итеп [1] куйды.

Шәриф бер аягын сузып, бик кәефле, тәмам нәшат берлә [2] тирләп чәй эчә, үзенең бу халыкларга баш икәнене белдереп тора иде.

Чәй эчеп, күңеле ачылгач, үзенең бу көн ничек теге марҗадан әйбер күтәреп барган өчен унике тиен акча алганыны бик озын итеп хатынына сөйләде. Бу сүзләре илә үзенең мал таба торган кеше икәнене күрсәтә иде. Бәдри дә бер кайгысыз, һәр эшләре мөкәммәл [3] барган төсле иттереп чәй эчә, тубыгы янында яткан икмәккә карап куя, иренә яхшы гына җаваплар биреп, син безгә вәлиниг ъмәт [4] дигән төсле карый иде.

Гөлҗиһан икмәгенең яртысыны ашап, яртысыны чәй илә кушып эчәргә самовар төбенә куеп, аның өстенә бик зур төсле иттереп шикәрне куйды да анасына карап: «Менә боларны чәй берлә кушып эчәрмен», — дип гуаһландырып куйды. Үзе самоварның аягыны бер кулы илә тотып карап утырды. Әзрәк торгач, акрын гына анасына карап: «Әни, миңа чәй ясап бир әле» дигәч, Бәдри эчә торган чәене эчеп бетереп, сыек кына иттереп ясап, Гөлҗиһанга бирде. Менә Гөлҗиһанның һәр эше тәмам җиренә килде. Шикәре илә бергә кушып, икмәкне дә ашап бетереп, торып китте. Инде нәүбәт Ходайбирдегә килде. Аңа да анасы чәй ясап биргәч, чәйне эчеп тәмам иткәч, тиз генә мич башына менеп, тараканнар илә уйный башлады. Шәриф ике

---

[1] Тәэкид итеп — беркетеп.
[2] Нәшат берлә — шатланып.
[3] Мөкәммәл — тәмам җитешеп.
[4] Вәлинигъмәт — аш хуҗасы, тәрбияләүче.

телем икмәкне ашап бетергәч: «Кайда әле, азрак кисеп бир» дигәч, Бәдри кисеп бирергә дип, икмәкне кулына тоткач та, мич башыннан Ходайбирде төшеп, йөгереп, анасы янына килеп утырды. Моның күзе икмәк сорап тора иде. Бәдри юка гына иттереп Шәрифкә кисеп биргәч, икмәкнең чамасыны карап белгәч, бик юка һәм кыек итеп кисеп Ходайбирдегә бирде. Ходайбирде шатланып, йөгереп менеп китте. Бәдри Гөлҗиһанны да мәхрүм итмәде, аңар да кисеп бирде. Үзе дә азрак алды. Шулай итеп, бик рәхәт һәм кайгысыз чәй эчеп тәмам иттеләр.

Шәриф дәхи кәсеп эзләп китәргә уйлап, чабатасыны алып, чүпрәкләрне урап киенергә кереште. Чабатасының астыны карап, әле нык икән дигән кеби, бармагы берлә тык-тык чиертеп-чиертеп карап, киенеп бетте. Чикмәнене киенеп, иске кызыл яулыгыны муенына урап, балтасыны алып чыгып китте.

Шәриф чыгып киткәч, Бәдри калган чәйне эчеп утырганда, күрше фатирда торган Шәех исемле егетнең хатыны Җәмилә килеп керде. Җәмиләнең кыяфәте тормышы агыр бер хәлдә, дөньяның бетмәс мәшәкатьләрендә идекене белдереп тора иде. Төсе саргайган, күзләре эчкә батып кергән, өстенә иске генә күлмәк кигән, башына ертылып беткән яулыгыны ураган, аягына тузып, мысклары чыккан чабата кигән иде.

Үзенә караганда аннан һәр кеше нәфрәтләнә, аны беркем дә яратмый, бер кеше дә аны кызганмый төсле иде. Шуның өчен Бәдригә дә кыяр-кыймас кына өметсез бер тавыш илә: «Исәнмесез әле?» диде.

Бәдри: — Әле арубыз, диде дә чынаяк астына чәй ясап, алдына куйды. Баягы икмәктән, бик чамалап кына кисеп бирде. Бәдри икмәк тотканны күргәч тә Ходайбирде килеп җитте. Бәдри, бар инде, азрак торгач ашарсың, дип кире җибәрде.

Җәмилә икмәкне кулына алу илә зур-зур кабып ашый башлады. Сары йөзендә аз гына якты чырай заһир булды. Шул бер телем арыш икмәгене әллә кайчаннан бирле күрмәгәнгә, чын күңеле илә, кайдан гына бер авыз тутырып кабарлык икмәк табылыр икән, дип йөргәнгә күрә, ул бер телем арыш икмәге аның өчен бер кыйммәтле нәрсә кеби күренә иде. Җәмиләне шул икмәк мәсьәләсе саргайткан, ул шуның өчен бу хәлгә

калган, шул икмәк юклык аны кәефсезләндергән вә авыру сурәтенә керткәндер.

Икмәк ашап беткәч, «бетте дә... тагы аз гына булса!» дигән төсле иреннәрен ялап, алдындагы валчыкларны чүпләп кабып куйды. Аз гына күңеле ачылып, иркев бер сулу алып, ясалып бирелгән чәйне эчте.

Бәдри үзенчә бик зур ихсан кылган, бер кешенең рәхәт тормышына сәбәп булган кешеләрчә: — Я, Җәмилә, бу көн ирең кая китте? — диде. Җәмилә (күңелсез, бер дә җавап бирәсе килмәгән кеби): — Ул иртә үк торып, эш булмас микән, дип чыгып китте, белмәем кайчан кайтыр икән. Кичә дә төн уртасында гына өйгә кайтып керде. Балтасыны әллә инде сатып эчкән, кайда дисәм, әйтмәй, үзе исерек (озын бер сулу илә), кичә дә бер дә ашамый яткан идем, менә инде бу көн дә ашаганым юк. Бу көн иртә үк торып, теге урамга барып, йомычка алып кайтып, өйне җылытып алгав булдым.

Б ә д р и (үзе бәхетлерәк бер кеше кеби): — Бигрәк начар инде, солдат кеби тик йөри, оятсыз!

Җ ә м и л ә: — Шулай инде. Әле синең бишмәтеңне сорап торырга килгән идем, каланың бит әле теге очында безгә апа тиешле Гөлниса бар, алар яхшы гына торалар. Шунда барып кайтыйм дигән идем. Әллә әзмәз нәрсә сорап кайтыр идем.

Б ә д р и: — Минем үземнең дә барасы җирем бар иде дә, алай булгач, алып торсаң торырсың шул инде. Әле яңа гына теге чәй эчеп чыгып китте. Бу көн иртә үк торып, эш эзләп чыккан иде. Менә инде бер яхшы марҗа очраган! Әйберләрене күтәрешеп алып барган өчен дә унике тиен акча биргән. Әле, ходайга шөкер, бу арада бер дә аптыраганыбыз юк.

Җ ә м и л ә: — Әйе! Сез, Бәдри апа, бик яхшы торасыз. Әнә минем ирем кебек булса, ни эшләр идегез. Тапкан бер акчасыны шунда бетереп кайта.

Б ә д р и : — Әлхәмделилла, шайтан ярлы, без бай әле, — диде дә бишмәтене кулына тотып, әле дә бу бишмәт булды! дигән төсле, Җәмиләдән үзен бәхетлерәк кеби күреп китереп бирде дә, — я әле, киеп кара, сиңа озын түгел микән? — диде.

Җ ә м и л ә: — Озын булмас, буламы? — диеп киеп карап, — таман гына икән, үземә үлчәп кистергән дип белерсең.

Б э д р и: — Бу бишмэт бик нык булды инде, өстемнән салмый киям, бер дә тузуны белми.

Җ э м и л э: — Әле дә өр-яңа әле, гомеремдә шундый бер бишмэт күрә алмадым, — дип чыгып китә башлый.

Б э д р и: — Җәмилә! Тизрәк кайт, ямс, үземнең суга барасым да бар...

Җ э м и л э: — Бик тиз кайтам, анда бер дә тора торган эшем юк, барам да кайтам.

Б э д р и: — Бичара, бик авыр тора инде. Ире дә бик начар шул, матур гына хатынны шулай ач калдырып йөрергә ничек оялмый, типсә, тимер өзә торган егет, ялгыз хатынын туйдыра алмый, — дия үз-үзенә сүзләнеп самоварны җыештырып куя да, боз катып ябылмый торган ишекнең бусагасыны пычак белән кырып ябарга керешә. Юка гына тактадан ясалган җеп-җиңел ишек каты итеп япкан саен кире ачыла да китә.

Җәмилә, бишмәтне кигәненә шатланып, артыннан килерләр дә бишмәтне кире алырлар төсле булып, үзенә калса, бик калын киенгән, бер дә салкынга бирешерлек түгел төсле, шәп-шәп атлап, тауга карап менеп китте.

## II

Шәриф чәй эчеп, җылынып алгач, бер дә кайгысыз, әллә ничек бик тиз эш табылыр кеби булып, тиз-тиз бара иде. Күп тә йөрмәде. Бәхетенә каршы эш тапты. Менә утын ярырга кереште. Бер бәхет ачылса, ачыла торган дигән иде, филвакыйгъ[1] шөйлә тугры килде. Эченнән әллә ниләр уйлаган кеби аллага шөкер итеп, чын ихлас белән яра иде. Хосусан хуҗа килгән вакытта бик уңган, вә бик эшлекле икәнне белдерер өчен ялтырап йөри, әүвәлдә ярылган утыннарны хуҗага күрсәтеп, менә моны бик эре итеп ярганнар, ахры бер дә эш рәте белмәгән кеше яргандыр, фәлән дип, сөйләнә иде. Утын хуҗасының бер мәртәбә килеп каравы аның күңелен үстерә, гайрәт бирә, вак кына итеп яруга сәбәп була иде. Утын яра торган тумарның өстенә утырып, бик җайлап истикъбале[2] тәэмин ителгән кешеләрчә, бик күңелле сурәттә тәмәкесен тарта, үзенчә бик

---

[1] Ф и л в а к ы й г ъ — чынлап та.
[2] И с т и к ъ б а л е — киләчәге.

ләззәт илә шөйлә уйлый иде: — Бу кафер кырык тиен бирмәс микән? Бирер, бирер, илле тиен биреп куймасын, бу утын саженьнан күп артык бит, юк инде, кырык тиен генә бирсен, шул да җитәр. Күптән бирле ит ашалганы юк иде — бераәр егерме тиенлек ит алып кайтсам, егерме тиен кала. Егерме тиеннең биш тиен көмешенә токмачка он алсам, аннан да унбиш тиен артып кала, унбиш тиенгә биш кадак икмәк алып кайтсам...

— Менә байлык!

Икенче рәт тәмәке тарткан чакта бу планны бозып:

— Юк, итне егерме тиенгә үк алырга ярамый, унбиш тиенлек алсам, җитәр, аннан калган биш тиенгә чәй алырга кирәк, — ди иде. Бераздан соң күңеленә өченче фикер төште. Бу фикер ит алмый гына, тояк, эчәк-фәлән алып кайту иде.

Менә инде, ул итне алып кайтып пешергәч, ничек итеп утырып ашарга! Үзене мал табучы һәм ата, аларга баш, вәлинигъмәт төсле эре күрсәтеп ашауларыны хыялыннан кичереп ләззәтләнә, шул уй аркасында 20—25 дәрәҗә салкында теттереп утын яра иде.

Кояш батмады, бар утынны тәмам ярып бетереп, гайрәтле бер сурәттә хезмәт хакыны сорады. Хуҗа канечкеч саран түгел икән! Шәриф уйлаганча кырык тиен көмеш хезмәт хакы өчен биреп, яхшы ярган өчен биш тиен дәхи биреп куйды. Шәриф бияләйне култыгы астына кыстырып, янчыгыны алып акчасыны санап салды да, бик күп маллы кеше кеби, эре генә атлап туры ит базарына китте.

Бу кырык биш тиен акча Шәрифнең ихтыяҗына камил җиткән, моннан күп булса — урыны юк, тотар урын булмагач, нигә кирәк, моннан күп булса, әллә нигә мазасыз булыр төсле күренә иде.

Ул, Шәриф, икмәк, чәйдән артып калган биш-ун тиен акчасына һәрвакытта урын таба алмый, ничек булса да тотып бетереп кайта торган иде. Мәсәлән, бер көн артып калган биш тиен акчасына нәрсә алырга белми, күзенә күренгән иске тимер кисәкләре алып кайткан иде. Менә бу вакытта да айың корган планыны тегe артык биш тиен бозды. Ул биш тиенгә нәрсә алырга кирәк? дип юл буенча уйлап барды. Акча булса, урын табыла инде. Шәриф биш тиенгә дә урын тапты.

Чөнки бер бәйрәм булгач, булсын инде диде дә биш тиенлек шикәр алып кайтырга карар бирде.

# *Фатих Әмирхан*

*(1886—1926)*

## ТАТАР КЫЗЫ

I

**Туды...**

**Туганда ул кеше иде: аякларын-кулларын үзе телəгəнчə селкетергə ихтыярлы, муенын телəгəнчə борудан, күзлəре белəн телəгəн җиргə караудан берəү дə аны тыя алмый иде.**

Бəгъзе вакытларда, кулларын-аякларын билəүгə чорнап, аны хəрəкəтлəнмəскə мəҗбүр иттелəр, лəкин ул моңар протест итəргə, риза түгеллеген белдерергə кодрəтле — елый ала, кычкыра ала: үз хөрриятен бирəүдəн дə югалттырырга риза түгеллеген, ирексезлəүчелəрнең күзлəренə туп-туры карап, белдертə ала иде.

Туганда ул кеше иде: көлəргə — шулай итеп, үз алдына, хəзер генə килеп чыккан тормыш, дөньядан шатланган, рəхəтлəнгəн икəнен берəүдəн дə курыкмый изһар итəргə, кирелəнергə — шулай итеп, үзендə «телəү, телəмəү» дигəн бер-берсенə һич охшамый торган сыйфатлар барлыгын, табигать тарафыннан фəкать шул

ике сыйфатка карап эш итәргә куәсе[1] бирелгәнлеген күрсәтергә көчле иде.

Ул туды... Тугач, аны башкаларны — ир балаларны сала торган бишеккә салдылар; анасы үз күңелендә, ир балалары белән янәшә үк җирдә, аңар урын бирде, ир балалары белән бер дәрәҗәдә үк мәхәббәт итте, сөйде; атасы да шулай ук итте. Өйдә вакытта ул ирләр тора торган үк бүлмәдә тора, тышка чыкса, ирләр йөри торган үк җир өстендә күтәреп йөртелә, ирләр җылына торган үк кояш белән җылына, ирләр туңа торган үк суыктан туңа, ирләр шикелле үк күңеленә килгән нәрсәне үзенчә уйларга, үз фикеренә, рухына, гакылына килгән нәрсәләр белән ирләр шикелле үк тәэсирләнергә хаклы иде.

Юмарт кояш аны алтынлы нуры белән чолгый, җил аның борынына язның шатлык, хәят[2], ләтафәт[3] белән тулы исен китерә, яңа үсә башлаган чәчәкләр дә көләч йөзләре белән аңар карыйлар — әлхасил, бөтен табигать моны башка адәмнәр белән бер дәрәҗәдә күрә, башкаларга биргән бүләген моңар да бирә иде.

II

Туды... Туганда ул терек иде. Ләкин аның бөтен терeклек вакыты алты яшенә җиткәнче генә сузылды. Аннан соң ниндидер мәлгунь көч үзенең берәүгә дә мәгълүм түгел мәхкәмәсендә[4] гөнаһсыз «татар кызын» үлем җәзасы — хәятсызлыкка хөкем итеп, акрын гына буарга кереште. Шәфкатьсез кысу машинасы арасына салып, хәят тамчыларының ахыргысы тамганчы кысарга, тән суынмас, йөрәк тибүдән туктамас борын хәятсызлык каберенә күмәргә карар бирде.

«Татар кызы» алты яшенә җитте... Биш яшьлек энесе яки җиде яшьлек агасы бәгъзе вакытта аны чәченнән тартып елата, бәгъзе вакытта сугып китеп, золым итә

---

[1] Куәсе — көче.
[2] Хәят — тормыш.
[3] Ләтафәт — матурлык.
[4] Мәхкәмә — хөкем йорты.

башладылар. Ул, һәрбер зи хәят[1] шикелле, бу җәберләргә үз көче белән каршы торырга тели, сукканга — суга, чәчен тарткан кешенең бармагын тешли, битен тырный иде. Кара көч үзенең үлем җәзасына хөкем иткән корбанның кулында бу — хәят хассаларыннан булган берсенең моннан соң да калуына риза булмады: «ана» исемле җанлы курчактан: «Кыз бала ир малайлар белән сугышып йөрми», дип әйттерде. Бу көннән соң «татар кызына» ага-эне җәберсеннән башкалар көченә сыгынып саклanырга әмре һәмаюн садир[2] булды.

Тәҗрибәсез кызчык алданды. Үзенең үлемгә хөкем ителүеннән һәм бу һөҗүм җәзасының башы икәненнән аның хәбәре юк иде.

«Татар кызы» җиде яшенә җитте... Ул моңар кадәр үзе шикелле балалар — ир балалар белән урамга чыга, анда чаба иде. Ләкин кара көч үз корбанының бу хәленә риза булмады. «Ана» исемле җанлы курчак: «Кыз балага ир малайлар белән уйнап йөрү оят!» дигән җөмләне тәкълитчә попугай мәһарәте белән тәкрар итте[3].

«Татар кызы» бу кадәр табигатькә, хәятка, хөрриятькә, кешелеккә хилаф[4] сүзгә ышана алмагач, кара көч эшкә чынлап тотынды. Атасыннан да шул ук сүзләрне әйттерде:

— Кыз балага ир малайлар белән уйнап йөрү оят!

«Татар кызының» ышанмавы какшый башлады. Әтрафтагы башкалар да шул ук сүзләрне тәкрар иттеләр:

— Кыз балага ир малайлар белән уйнап йөрү оят!

«Татар кызы» ышанды. Чөнки ул адәмнәрнең һәммәсен үзе шикелле сафлар дип белә иде. Хәят үзен химая итәргә[5] тотынды. Ул үзенең дошманнарын, гакыл мөхакәмәсенә тартып, җиңәрмен дип уйлый иде.

— Ник? — дип сөаль[6] бирде.

---

[1] Зи хәят — җан иясе.
[2] Әмре һәмаюн садир — югарыдан әмер.
[3] Тәкълитчә попугай мәһарәте белән тәкрар итте — ияртүче попугай осталыгы белән кабатлады.
[4] Хилаф — каршы.
[5] Химая итәргә — якларга.
[6] Сөаль — сорау.

«Татар кызы» сүз дәшмәде, аның урынына кара көч җавап бирде:

— Чөнки эти, әни, бабай, әби шулай диләр.

Хәят аптырашта калды. Үзенең бу кадәр әсассыз[1], бу кадәр мантыйксыз, хәтта бу кадәр кешелеккә килешми торган җавап ишетәсен аның бервакытта да уйлаганы юк иде. Бу кадәр көтелми килгән бәлагә каршы аның кулында бер корал да булмады, шулай итеп, үз хассаларыннан иң зурларын: золым вә җәберләргә үз көче белән каршы тора алу һәм башкаларга яраган эшнең үзенә дә яравын хис итеп, үзен хөр күрүне югалтты.

Кара көч бу галәбәсен[2] бик шатлыклы бәйрәм белән каршылады һәм, корбаны — «татар кызын» ниһаять тәхкыйрь иткәнлеген күрсәтер өчен, аның кулына кечкенә-кечкенә җансыз курчаклар ясап тоттырды.

Башка балалардан, иркен һава, иркен дөнья, иркен йөрешләрдән аерылган «татар кызы» кара көчнең бу бәдбәхет бүләген мәҗбүрән кулына тотты, әйләндергәләп карый башлады. Ул аларның нәрсә өчен ясалганлыкларын белми иде.

Кара көч, «татар кызы» янына апа, җиңгә, ана, әби... дип төрле исемнәр белән атала торган җанлы курчакларны җибәреп, җансыз курчаклар белән ничек уйнарга кирәклеген өйрәттерде. Җанлы курчакларның чын игътикатларынча: җансыз курчакларны кунакларга йөртеп, туйлар ясатып, кияүләр кертеп, киленнәр төшертеп, кодагый, кодачага бүләкләр бирештереп... уйнарга кирәк иде.

«Татар кызы» бу сүзләрнең чын мәгънәләрен яхшы аңламады. Ләкин ир балалар белән уйнавы оят хисап итела торган кыз балага башка уеннар калмаган да иде. Табигый, кара көчнең шомлы бүләге белән уйнарга башлады:

— Менә бу ир курчак. Ләкин монысы кыз. Ир курчак кыз курчакны хатынлыкка алды; кияү керде; килен төште, кунакка килде...

«Татар кызы» уйный, уйный да уйный.

Кара көч, почмакка басып, елмаеп карап тора:

— Менә бу — синең киләчәккә хәзерләнүең! Бу — киләчәктәге үз тормышың!

[1] Әсассыз — нигезсез.
[2] Галәбәсен — җиңүен, өстен чыгуын.

## III

«Татар кызын» сабак абыстасына бирделәр. «Галине, Вәлине, Биктимерне мәктәпкә бирделәр, мине ник абыстайга бирделәр?» дигән «урынсыз» сөаль «татар кызының» фикеренә килгән иде, ләкин озакка бармады, кара көч ду кубарды:

— Кыз балаларга ир малайлар белән бер җирдә укырга ярамый!

Җанлы курчаклар, башларын селкеп, тәсдыйк иттеләр [1]:

— Әйе, әйе, ярамый!

Хәят бу дәфгадә [2] дә, үзен химая итмәкче булып, сөаль биреп карады:

— Ник? Ник ярамый?

Җанлы курчаклар акырыштылар:

— Оят була, оят була, оят була!

«Ата» үзенең «ир гакыллы» башы белән тәсдыйк итте:

— Оят була, оят була!

— Ник?

«Ата» үзенең кыскартылган мыекларын кабартты. Җанлы курчаклар йөзләрен җыердылар, шулкадәр җыердылар ки, боларның курчаклар икәнен белмәгән кешеләр куркып яннарыннан качар иделәр:

— Ник, имеш! Чөнки оят була! Оят була!

Монда җиткәч, кара көчкә максудына ирешү мәшәкатьсезләнде: иң авыр вазифа — кара көчнең бик күптән бирле ышанычлы хезмәтчесе булып килгән «сабак абыстасы» исемле җанлы курчакка йөкләнде. Абыстай үз вазифасын [3] яхшы белә, аңар «татар кызын» үзе шикелле җанлы курчак ясарга кирәк иде. Кара көчнең илһамы, үзенең кырык еллык тәҗрибәсе белән, ул «татар кызын» җанлы курчак ясарга иң кыска һәм иң асат юлны тапты: «татар кызына» өч ел мөттасыйль [4] «ирләр башка, кызлар башка» дигән «хакыйкатьне» төрле якларыннан һәм төрле юллар белән өйрәтте. «Татар кызына» бу тәгълим [5] гаҗәп тоелмады, өендәге җанлы курчаклардан моны бик күп мәртәбәләр ишеткән иде.

---

[1] Тәсдыйк иттеләр — расладылар.
[2] Дәфгадә — минутта.
[3] Вазифасын — бурычын.
[4] Мөттасыйль — тоташтан.
[5] Тәгълим — өйрәтү.

Абыстай алгарак китте: «татар кызының» колагына өч ел мөттасыйль: «Син вә бөтен хатын-кыз җәмәгате — гаурәт», дип тукып торды.

Башта хәят моңар каршы бик нык протест ясады:

— Ялган! Мин гаурәт түгел — кеше! Мин кеше!

Кара көч абыстайга илһам итте; абыстай да «татар кызының» алдына бик күп язма вә басма документлар чыгарып салды. Бу документларның һәммәсенә «бөтен хатын-кыз такфәсе — гаурәт» дип язылган иде.

Хәят тырпылдады. Гаять тә тәгаҗҗеп һәм ачу белән тагы бер кат:

— Ник? — дип сорады.

Абыстай, документларны күрсәтеп:

— Китап шулай ди, — дип җавап бирде.

Кара көч «татар кызына» йодрык күрсәтте:

— Зурлар әйткәнгә ышанмый кара, мин сине!

## IV

«Татар кызы» унөч яшькә җитте...

Җанлы курчакларны адәм күзеннән саклый торган, кояшка, айга, һавага күрсәтми торган, юллы-юллы, калыпсыз капчыкны «татар кызына» да бирделәр.

Өйдәге җанлы курчак:

— Кызым, сиңа унөч яшь тулды. Бу көннән соң кабереңә кергәнче башыңа шушы нәрсәне бөркәнеп йөр! — диде.

Кызыл сакаллы, кыска мыеклы «ата» тәэкид итте[1]:

— Минә шушы нәрсәне кабереңә кергәнче бөркәнеп йөр!

«Татар кызы» бернәрсә дә аңламады, сызланып, фөрьяд[2] итеп сорады:

— Ник?

Җанлы курчаклар җавап бирмичә генә өстәделәр:

— Кырган башына бүрек кигән «ир кеше» атлы нәрсәләргә очрасаң, башыңа бөркәнгән бу нәрсәнең чите белән йөзеңне капла!

Хәят канлы яшьләр агызып сорады:

— Ник?

Җавапны абыстай бирде:

---

[1] Тәэкид итте — беркетте.

[2] Фөрьяд — ачынып кычкыру.

— Синең чәчләрең, йөзең, бөтен гәүдәң — гаурәт. Гаурәт каплап йөртелә. Сиңа ирләр башкачарак карыйлар, шуңар күрә син алардан качарга тиеш!

Хәятның үзенә шулкадәр хәкарәт нишеткәне юк иде.

Ахыргы җөмләне «абыстай» «татар кызының» колагына ике ел мөттасыйль кычкырып торды:

— Ирләр сиңа фәләнчә карыйлар!

Хәлсезләнгән, парчалары кырылган хәят бу юлы «ник?» дип сорарга җөрьәт итә алмады: кара көч, тешләрен ыржайтып, йодрык белән куркытып тора иде.

Җанлы курчаклар «татар кызына»:

— Сиңа унбиш яшь тулды, моннан соң ирләргә буеңны күрсәтеп, сабакка йөрүең оят! — диделәр.

Хәят бу вакытта бик каты авыру иде — игътираз итмәде[1]. Кара көч тә бик нәсыйхәнә[2] генә тәэкид итте:

— Син үзеңнең ирләр белән бер түгел икәнеңне, гаурәт икәнлегеңне, кешегә күренүең оят икәнне белдең инде. Сиңа шул гына кирәк иде. Шуннан артыкны белүең оят! Оят!

## V

Җанлы курчаклар һәм зур корсаклы «ата» «татар кызына» катгый әмер бирделәр:

— Менә сиңа дүрт дивар[3], үзең белән уйнарга «ир» дигән бер хайван табылганчы, шуларны сакла, алардан үзеңне саклат!

«Татар кызы» бу сүзләрнең чын мәгънәләрен аңламады. Кара көч тәфсыйль бирде:

— Алты өлгеле тәрәзә сиңа кояш булыр; өйнең биш бүлмәсе Европа, Азия, Африка, Америка һәм Австралия булырлар, тәрәзә аллындагы зәгыйфь гөл кисәкләре урманнар, кырлар, бакчалар урынына хезмәт итәрләр; комган вә ләгәндәге тынчыган сулар сиңа елгалар, күлләр, диңгезләр урынына ярарлар; күмер, куй мае, гатырша мае исләреннән җыелган, сулышлар белән агуланган һава сиңа бөтен җир йөзендәге һава гыйвазенә[4] булыр; өеңдә һәркөнне ишетә торган кычкырыш, тиргәш, елашлар сиңа музыка урынына булырлар, миллиард

[1] Игътираз итмәде — каршы сүз әйтмәде.
[2] Нәсыйхәнә — үгетләп.
[3] Дивар — стена.
[4] Гыйвазенә — урынына.

чрым гадәдле[1] бәни адәм урынына 7—8 җанлы курчаклар һәм «атаң» булыр; меңнәрчә еллар бәни адәмнең иҗтиһады белән вөҗүткә килгән[2] фәннәр һәм фәлсәфә урынына «мөкатдәс» наданлыгың булыр!

Хәят бер мәртәбә «аһ!» диде, башкага хәлсез иде.

Көннәр уза башладылар. Ләкин үлем дәрәҗәсендә авыру хәят бу зинданда бер дә хәрәкәтсез генә буылырга риза булмады — «татар кызын» тәрәзә янына илтте. Җомга көн иде. Тәрәзә янынннан кәкре аяклы бер кибетче узып китте. «Татар кызы» кибетчегә «гыйшык» булды. Кибетче дә, йөрешен купшыландырып, күзләрен ялтыратып: «Матур тәтәй, ник ялгыз утырасың?» дигән шикелле бер «гыйшык» сүзе белән җавап бирде.

Шимбә көн «татар кызына» тәрәзә алдында утырмаска әмре һәмаюн садир булды: «татар кызы» бүген тәрәзә алдында йөренә генә иде. Тәрәзә алдыннан көянтә шикелле урталай бөкрәйгән «татар шәкерте» узып китте. «Татар кызы» моңа да «гыйшык» булды. Шәкерт тә үз тарафыннан: «Каләм кашым, хурыльгайнем[3]» дип җавап бирде дә бүген үк чәчәк төшерелгән «тәти» кәгазьгә хат язарга карар бирде.

Якшәмбе көнге әмре һәмаюн «татар кызына» тәрәзә янына килүне бөтенләй мәнгы итә[4] иде. Ул урлап, качынып кына тәрәзә янына килде. Урамнан хәзер генә кырдырган башына койрыксыз чалма кигән «мәхдүм» узып бара иде. «Татар кызы» моңар да «гыйшык» булды. Мәхдүм әфәнде дә чалмасын матурлабрак төзәтеп киде һәм, бер күзен кысынкырап, бай кызына өйләнүнең файдаларын уйлады; бүген үк бер карчык аркылы кызга «бик сагынып, бик саргаеп, сәлам күндермәкче» булды.

Дүшәмбе көн «татар кызы» тагы, бер вакыт табып, качынып, куркынып кына тәрәзә янына килде. Урамнан яхшы атка утырып, зур корсаклы «татар бае» һәм майлы күзле, кыңгыр бүрекле «бай бәтчә» узып баралар иде. «Татар кызы» бай бәтчәгә «гыйшык» булды. Бай бәтчә дә, кашын сикертеп, бишенчегә бу кызны да сөяргә мөмкин икән дип уйлады. Карт бай да вакыты белән моны икенче хатынлыкка соратмакчы булды.

---

[1] **Гадәдле** — санлы.

[2] **Бәни адәмнең иҗтиһады белән вөҗүткә килгән** — кешенең тырышлыгы белән барлыкка килгән.

[3] **Хурыльгайнем** — хур кызым.

[4] **Мәнгы итә** — тыя.

## VI

Кара көч хәятның бу үлем алды хәрәкәтләренә дә риза була алмады.

Җанлы курчаклар «татар кызына»:

— Хәзер сине читекче Биктимергә кияүгә ярәштек. Син аңар хезмәт итәргә бурычлы, — дип игълан иттеләр.

Акыллы баш «ата» амиранә[1] тәэкид итте:

— Читекче Биктимер ризасы — тәңре ризасы!

Кара көч бу сүзләрне раслады:

— Син хәзер хәят дигән революционердан бөтенләй котыласың, җанлы курчак булып каласың. Мин синең белән уйнарга читекче Биктимерне тәгаен иттем[2]; кабереңә кергәнче шуңар хезмәт итсәң, минем максудым була.

Җанлы курчак сатучы «ата» белән улына уенчык ала торган «ата» арасында сәүдәләшү башланды.

— Юк, Зәйнетдин абзый, мәһәр биш йөз сум тәңкә!

— Алай кыйммәт, хәерле кулдан дүрт йөз сум!

— Юк, Зәйнетдин абзый, бер илле сум арттырырсың ла инде!

— Хәерле булсын, ука чачагы белән бер асыл күлмәк артык бирермен!

Әүвәл өйгә бик күп җанлы курчаклар чакырып ашаттылар. Алар һәммәсе булачак курчак «татар кызына» чүпрәкләр, тәтиләр китерделәр.

Аннан соң җанлы курчаклар белән уйнаучы ахмаклар төркемен чакырып ашаттылар. Болар арасында чалмалы бер кеше дә бар иде. Ул, бер әфсүн укып, хазирунга[3] өрде. Шул дәкыйкадән мәҗлестәге бөтен кешеләр «татар кызын» читекче Биктимернең уенчыгы дип игътикат итә башладылар.

— Сез, кем, фәләнетдин, солбия кызыңны[4] 400 сум акча, бер ука чачаклы асыл күлмәк бәрабәренә Биктимер Зәйнетдин углына бирдеңме?

— Бирдем, бирдем!

— Сез, кем, Зәйнетдин, «татар кызын» 400 сум акча, бер ука чачаклы асыл бәрабәренә солби углың Биктимер өчен кабул итеп алдыңмы?

---

[1] Амиранә — әмер итеп.
[2] Тәгаен иттем — билгеләдем.
[3] Хазирунга — шундагы кешеләргә.
[4] Солбия кызыңны — үз кызыңны.

— Алдым, алдым!

«Татар кызы» белән Биктимерне дүрт тәүлек ябып тоттылар. Килен итеп төшерергә хәзерләделәр. Җанлы курчак «татар кызына» ахыргы нәсыйхәтләрен бирде:

— Кызым, ирецнец сүзеннән чыкма; аягы астында туфрак бул!

Гакыллы «ата» тәсдыйк итте:

— Читекче Биктимер ризасы — тәңре ризасы!

Бу вакытта хәятның тавышы чыкмаганын күргәч, кара көч гаять шатлык белән «татар кызына» карап, бер каһкаһә итте:

— Менә инде син җанлы курчак булып җиттең!

## VII

«Җанлы курчакны» Биктимер дүрт дивар арасына кертте дә диде:

— Менә сиңа диварлар, каберецә кергәнче син шуларны сакларга тиеш. Мин теләгән вакытта килеп синең белән уйнармын.

Кара көч, почмакка басып, амиранә өйрәтте:

— Синең вазифаң иреңә уенчык булу һәм үзегез шикелле ахмакларның җир йөзеннән нәселләре киселмәсен өчен бала табу!

Биктимер «җанлы курчакка» күзләре белән ишарә итте, «җанлы курчак» та, кара көч алдында мөтәвазыйганә рөкугъ итеп [1], диде:

— Беләм, бик беләм, минем дөньяга чыгарылуымнан максуд шул ике нәрсә генә.

Кара көч, хәят тавышын хәзер дә ишетмәгәч, кычкырып көлде:

— Ха, ха, ха, татар кызын «җанлы курчакка» әйләндердем бит!

Торган почмактан чыгып, нәкъ урта бер җиргә килеп басты, яңадан көлде:

— Ха, ха, ха, «татар кызын» терелəй күмделәр бит!

Бу вакытта Мисырның җәмигыль әзһәрендә [2] талиплар, Истамбулның милләт хокукын мөхафәзә исеменә тәрбия ителә торган парламенты күршесендә, Аясофия

---

[1] Мөтәвазыйганә рөкугъ итеп — буйсынып, башын иеп.

[2] Җәмигыль әзһәрендә — мәдрәсә исеме.

җамигында сохтәләр [1], Сәрәндип [2] атавында, дарчин агачлары арасында Һинд мөселманнары, Курса мәдрәсәсе почмагында суфилар, шәһәре Болгар хәрабәләре арасында сәях мөселманнар һәм кәгъбәтуллада бөтен икътары әрыздан [3] җыелган хаҗилар коръан укыйлар. һәммәсе:

«Вәизәль мәүүдәте сөиләт, биәйи зәнбин котиләт» [4] аяте кәримәсен тәкрар итәләр иде:

Вәизәль мәүүдәте сөиләт, биәйи зәнбин котиләт.

---

## ГАБДРАХМАН ИЛЬЯСИ

## (1856—1895)

Габдрахман Ильяси — XIX йөзнең соңгы чирегендә татар әдәбияты тарихында драмадан беренче әсәр биргән язучы. Каюм Насыйри нигезләгән яңа татар әдәби телен үстерү буенча да ул практик эшчәнлек күрсәтүчеләрнең берсе булды.

**Биографиясе.** Габдрахман Ильяси 1856 нчы елда Казанда сәүдәгәр семьясында туа. Ләкин атасы Мөхәммәтдәмин, бөлеп, зур бурычка керә. Үзеннән соң бурычны түләү мәшәкате улы Габдрахман өстенә төшә. Йорт-җирләре дә шул бурычны түләүгә керен китә. Габдрахман Ильяси төрле байларда конторщик һәм хисапчы булып эшли, гомеренең соңгы елларында материаль яктан шактый авыр хәлдә калып, 1895 нче елда авырып үлә.

Габдрахман Ильяси Казанның иске мәдрәсәләреннән берсе булган Күл буе мәдрәсәсендә укый. Бу мәдрәсә мулла һәм хәлфәләр генә хәзерләп чыгаруны бурыч итеп куйганга, анда алган тәрбия һәм белем Г. Ильяси омтылган иҗат эшчәнлеге өчен, әлбәттә, файдасыз була. Шуна күрә Г. Ильяси, мәдрәсәдә укуыннан тыш, үзле-

геннән һәм аерым укытучыларга йөреп, русча укый, рус әдәбияты һәм культурасы белән, аз булса да, таныша бара, бигрәк тә рус театрлары белән кызыксына. Менә бу соңгы момент аның киләчәген билгели, аңарда язучылык дәртен үстерүгә сәбәп була.

Габдрахман Ильясиның мәгърифәтче Каюм Насыйри белән аралашуы аның эшчәнлеге үсүгә булышлык итә. Ул, Каюм Насыйри белән бергәләп, фәннәрнең нигезләрен үзләштерү өстендә эшли. Алар, җәй көннәрендә авылларга чыгып, табигатьне күзәтәләр, география, астрономия һ. б. фәннәрне өйрәнәләр.

**Иҗаты.** Г. Ильясиның әдәби мирасы зур түгел. Безгә бары ике әсәре генә билгеле. Аның беренчесе — 1887 нче елда чыккан «Бичара кыз» драмасы. Шул ук елны ул «Яшь кыз вә хатыннарга һәдия»[1] исеме белән икенче бер китабын да бастыра. 14 кенә биттән торган бу китапчыгында автор балаларны ничек итеп тәрбияләү кирәклеге турында фикерләр йөртә. Китабына язган сүз башында: «Насыйп булса, тиз заманда татар телендә хатыннарга махсус бер зур китап тәртип кылачакмын», — дип искәрмә бирүенә караганда, Ильясиның тәрбия мәсьәләләренә багышланган әсәрләрне тагын да язарга уйлаганлыгы күренә.

Г. Ильяси — үзенең әдәби-культура эшчәнлеген шактый киң алып барырга уйлаган язучы. Ул 1880 нче елларда татар телендә газета чыгарырга да омтылып карый, ләкин, патша хөкүмәтеннән рөхсәт ала алмавы сәбәпле, бу теләгенә ирешә алмый.

Болардан тыш, Г. Ильяси, К. Насыйри шикелле үк, тарихи вакыйгаларны күрсәткән кулъязмалар белән дә кызыксынган һәм Казан университеты янындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең җыелышларында докладлар белән чыгышлар да ясаган. Шул турыда ул вакытларда Казанда рус телендә чыккан «Волжский вестник» газетасының 1886 нчы елгы 98 нче номерында түбәндәгечә язылган: «...Җәмгыятьнең действительный члены А. А. Ильясов җәмгыятьне кызыклы бер татарча кулъязма белән (сәүдәгәр Аитов өендә табылган) таныштырды. Бу кулъязмада, үз күзе белән күрүченең сүзләренә караганда, Пугачевның Казанда булуы турында сөйләнә. Бу тарихи памятникның әһә-

---

[1] Һәдия — бүләк.

мияте шунда, ул Пугачев явы килгән вакытта Казан татарлары үзләрен ничек тотканлыкларын күрсәтә». Газетада басылган бу хәбәрдән күренгәнчә, Г. Ильяси Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең действительный члены булып торган. Бу аның үз вакытында танылган галим булуы турында сөйли.

**«Бичара кыз» драмасы.** Феодализм йомыклыгы шартларында көнкүреш, мораль һәм семья мәсьәләләрендә күп еллар буенча урнашып килгән искечә мөнәсәбәтләргә каршы, аеруча XIX йөзнең соңгы чирегендә, татарлар арасында да беренче үткен фикерләр күтәрелә. Алдынгы татар укымышлылары әдәбият аркылы иҗтимагый көрәшкә чыгарга омтылалар.

«Бичара кыз» драмасының сюжеты әнә шул иҗтимагый тормышта инде җитешә башлаган каршылыклар җирлегендә үсеп барган көрәш нигезенә корылган. Анда сурәтләнгән кешеләр үзләренең карашлары, омтылышлары белән бер-берсеннән аерылып торалар.

Пьесада төп урын тискәре образларга бирелгән; феодализм һәм капитализм тәртипләре, горсф-гадәтләре белән яшәүче, мораль яктан бертөрле дә уңай сыйфатлары калмаган типлар сурәтләнгән.

Тискәре образларның берсе — Б и к т и м е р. Ул, үзенең семьядагы өстенлегеннән файдаланып, бердәнбер кызын, бай малаена, эчеп-исереп йөрүдән башканы белмәгән, надан, аңгыра Җантимергә бирергә хәзер тора. Хатыны Фәрихәнең:

— Маһитап яратырмы икән? Уртарак[1] диләр, — дигән соравына ул:

— Мин риза булгач, шул җитә, — дип кенә җавап кайтара.

Шул рәвешчә, байлыктан башканы күз алдына да китерә алмаган Биктимер, кызының киләчәктәге тормышы, бәхете турында уйламый гына түгел, тормыш иптәше сайлаганда, кызга бертөрле дә ихтыяр куймый. Бу образда татар баеның башбаштак характеры, кешелексезлеге ачык күренә.

Автор Биктимерне кешене газаплаучы дип бәяли. Әсәрнең уңай образларыннан булган Җанбай теленнән:

---

[1] У р т а р а к — акылга уртачарак дигән мәгънәдә.

— Һай зобани, һәй җәллад![1] Ни кылдың үзеңнең газиз балаңа? — дип әйттерә.

Ачы нәфрәт белән әйтелгән менә бу сүзләрдән авторның да ул тормышка, Биктимер шикелле кешеләргә булган мөнәсәбәте һәм мораль изелүгә каршы яшьләрдә көчәя барган ризасызлык чагыла.

Тискәре характерлардан икенче образ — Җантимер әсәрдә тагын да кыска сурәтләнә. Аның турында башлангыч характеристика беренче пәрдәдә Маһитап монологында бирелә: «Кабахәт Җантимер», — ди Маһитап. Соңгы пәрдәдә, кыска гына бер эпизодта, Җантимер үзенең шундый кеше булуын тулысынча күрсәтә. Аның исерек хәлдә, алпан-тилпән килеп кереп, шунда егылып калуы укучыларда нәфрәт уята, чиркану тудыра.

Автор сурәтләвендә Җантимер «бик бай кешенең улы, ямьсез, аңгыра», байлыгына масаеп йөрүче, бертөрле дә уңай сыйфатлары булмаган кеше. Һәм ул, чыннан да, мораль түбән төшкән буржуа-мещан яшьләрен күрсәтүче реаль образ.

Тагын да драмада күрсәтелгән тискәре типлар арасында шул вакытның бер төркем хатын-кызлары характерын ачкан Сәхибә абыстай һәм яучы образлары да бар. Яучы образы — тупас, намуссыз һәм кыз димләү эшен бары үзенә «бүләк» китерә торган кәсеп итеп кенә караучы кеше. Ул ачыктан-ачык ялган сөйли. Гомере буенча башы исереклектән айнымаган Җантимерне мактап:

— Егетнең ашау-эчүе юк. Тәвәккәлләп бирү кирәк иде, — ди.

Сәхибә карчык образы пьесада байтак тулы күрсәтелгән. Ул — үзенең эш-хәрәкәте белән тупас рәвештә иске гореф-гадәтләрне саклаучы. Аның им-томчы карчык булуы һәм ниндидер догалар белән Маһитапны үзе теләмәгән никахтан коткарырга маташуы автор тарафыннан тәнкыйть ителгән. Маһитапның үзе теләмәгән кешегә барудан котылуы Сәхибә карчыкның им-томнары ярдәмендә түгел, бәлки яңа фикерле кешеләрнең булышлыгы аркасында гына булуы мөмкин икәнлеге күрсәтелгән.

**Маһитап образы.**

Драмадагы уңай образлардан иң күренеклесе — Маһитап. Кара фикерле бай семьясында үскән, ләкин яңачарак фикер йөртә башлаган Маһитап аталарының аны үзе

[1] Җәллад — палач.

яратмаган кешегә көчләп кияүгә бирүләре беләя риза була алмый.

Әсәр Маһитапның кичерешләрен сурәтләү белән башлана: «Маһитап (ялгыз). Аһ, һавалар, аһ, мәхлуклар... аһ, бәнем әхвалем... Сандугачлар сайрый, агачлар яфракка бөреләнә, нәфис хуш җилләр исәдер. (Бераздан соң янә.) Аһ, галәм[1] көннән-көн үзгәрәдер. Ләкин бәнем хәлем ничек үзгәрер; кояш чыгуы кебиме яки кояш батуы кебиме?».

Үзен Җантимергә бирергә җыенуларын ишеткәч, Маһитап: «Уф, мине... Җантимергә бирсәләр? Мин ни эшләрмен? Юк, юк, бармам... бармам... Минем ризалыгымнан башка бирмәсләр», — ди.

Маһитапның менә бу монологында үз тормышының киләчәген кайгырта башлаган, аңы үсә барган яшьләрнең мораль сыйфаты чагыла. Маһитап киләчәк тормышының «кояш чыгуы кебек» күтәрелгәнен күрергә тели, үзенең шәхси ирке, үз язмышына хуҗа булуы турында уйлана. «Минем ризалыгымнан башка бирмәсләр», — ди ул. Ләкин Маһитап үз хокукын үзе якларга көчсез. Ул киләчәкне дә тиешенчә күз алдына китерә алмый һәм иске гореф-гадәтләрнең колы булудан котылырга да сәләте юк. Шул рәвешчә, Маһитап образында автор үз чорының билгеле бер алдынгы карашлары йогынтысын да һәм иске тәрбия тәэсиреннән котыла алмауны да бергә җыйган типны, каршылыклы итеп, реалистик гәүдәләндерергә теләгән. Бу уңай образда хатын-кыз азатлыгы өчен башланган көрәшне чагылдыру омтылышы сизелә.

Әсәрдә уңай образларның икенчесе һәм Маһитапка булышлык күрсәтүче итеп Җ а н б а й бирелә. Җанбай — аңлы кеше. Ул газеталар укый. Ул үзе өчен генә яшәүче түгел. Аңарда башкалар өчен кайгыра белү, тырышу хисе көчле. Маһитапның үзе теләмәгән кешегә көчләп кияүгә бирелү хәбәрен ишеткәч, Җанбай: «Безгә яхшы әле. Бакчы, бүген Маһитапка зиндан, зиндан! Бак, нинди хафа, бичара, юк аны кызганучы. Ник башка кеше кызгансын аны, үзенең ата-анасы кызганмаганны... Аһ, бәгырем, берәү дә кызганучы юк. Юк, юк, мин кызганам, мин кызганам», — ди. Һәм ул, гасырлар буенча яшәп килгән иске семья тәртипләренә, шәригать закон-

---

[1] Г а л ә м — дөнья.

нарына буйсынмыйча, Маһитап янына бара, аны мәҗбүр ителгән никахтан коткара. Ахырдан без аларның теләкләренә ирешүләрен, ә Җантимер белән Биктимернең мәсхәрәгә калуын күрәбез.

Шулай итеп, Ильяси иске мөнәсәбәтләрнең җимерелә башлавын, семья, мәхәббәт һәм мораль мәсьәләсендәге яңа мөнәсәбәтләрнең җиңәргә тиешлеген расларга омтыла. Язучы хатын-кызлар азатлыгы мәсьәләсен күтәреп чыга. Ләкин автор үзе дә һәм аның уңай геройлары да бу мәсьәләне аңлауда бик чикле караштә торалар. Аларда хатын-кызлар ирекен аңлау мәсьәләсе семья эчендәге шәхси азатлык дәрәҗәсендә генә күз алдына китерелә әле.

Драмада, өстән генә булса да, асрау Фатыйма характеры да бирелгән. Автор беренче нәүбәттә Фатыйманың кешелекле булуын күрсәтә. Фатыйма, Маһитапның күрсәткән тупаслыкларына да карамастан, аның бәхетсезлеккә төшүен теләми, аны кызгана. Маһитапның исерек Җантимергә ярәшелү хәбәрен ишеткәч, тирәнтен борчыла: «Туташым, бәгырем... Сезне бит Тимербайның улы Җантимергә бирәләр...» — дип ачынып хәбәр итә.

Әсәрнең композициясе катлаулы түгел. Драма әсәре буларак, ул тик башлангыч хәлдә генә, зур пьесаның схемасы төсендә генә. Әмма бу пьеса, шул көенчә дә, үз вакытында җәмәгатьчелек фикере үсешенә билгеле бер уңай йогынты ясаган.

«Бичара кыз» драмасында автор яклаган төп фикерләр: беренчедән — хатын-кызларга семья эчендә генә булса да хокук бирү, аларның мораль ирекләрен яклау, икенчедән — укыган, аңлы яшьләрнең, малсыз булсалар да, аңгыра, тупас һәм бозык бай малайларыннан мораль өстенлеген, кешелеген күрсәтү. Үз заманы өчен бу проблеманы әдәбиятта яктырту, әлбәттә, әһәмиятле бер яңалык иде. Ул татар әдәбиятында күтәрелгән прогрессив идеяләрнең берсе булды.

«Бичара кыз» драмасының теле сүзлек составы ягыннан халык сөйләменә якын тора. Моңа китап телендә күп еллар буенча кулланып килгән, киң күпчелеккә аңлаешсыз әдәби стильдән котылуга таба бер адым дип карарга кирәк. Г. Ильяси татар гомумхалык теленә нигезләнгән әдәби телне үстерүне яклый. Шулай да аның телендә җитешсезлекләр һәм диалектизм эле-

ментлары шактый күп әле. Аерым очракларда риторикага бирелү һәм ясалмалылык та күренә. Г. Ильясиның «Бичара кыз» драмасындагы художество һәм стиль кимчелекләре тикшерелә торган дәвердәге татар әдәбиятының һәм аеруча драматургиясенең торышы тиешле югарылыкта булмавыннан килеп чыккан, әлбәттә. Шуларга да карамастан, бу пьесаның әһәмияте зур, чөнки анда шул чорның алдынгы карашлары билгеле бер күләмдә реалистик чагылган һәм чорга критика элементлары да гәүдәләнгән.

## ТАТАР ЯШЬЛӘРЕ

(1912)

Дыйккатә лаек хәзерге көн татарның яшьләре,
Аңламак, белмәк, тәрәкъкый, мәгърифәт, хикмәт белән

Әйләнеп һәм нурланып тормакта һәр дәм [3] башлары,
Мондый күрнеш сөенечennән инде мин алдан беләм:

Тик болар безгә кирәк диңгез төбе гауваслары [4].
Өстә бу ямьсез болыт баштан китәр, яңгыр явар,

Җиргә рәхмәт күк төшәр яшьләрнең изге касдлары [5];
Шаулап аккан су булыр тау башлары, тау аслары;

Күк булып күкрәр һавада хөр яшәү даулашлары;
Ялтырар изге көрәшнең хәнҗәре, алмазлары.

Йөрмәсен бәгъре өзек милләт киеп кашсыз йөзек, —
Без аның бик зур фәхерле [1], чын брильянт кашлары!

## ХӨРМӘТЛЕ ХӨСӘЕН ЯДКАРЕ

(1912)

Көч белән бергә гүзәллекне җыйган диңгез кеби,
Ул иде өстен вә кул җитмәс кеше, йолдыз кеби.

Әүлияларның барын бер-бер китерсәм каршыма,
Күрмәмен дип уйлыймын бер якты йөз ул йөз кеби.

Көчле, көчсез, ярлы, бай булды һаман да бер аңар,
Һәр караштa ул иде чын «керпегеннән гөл тамар».

Үтте тормыш пычрагын гәүһәр кеби вөждан белән,
Аз гына кер кунганын да кай җиреннән кем табар?

Ул көрәште һәм явыз эшкә җәза бирде көлеп,
Үткен акылы шул көлешкә пакь көмештән юл булып,

Ул көрәште, язда елмайган кояш төсле бәләнд [2],
Карны, бозны ул ничек эртә көлеп һәм нур коеп.

Күрмәде гами [3], табигый, буш куыклар атмагач,
Һәм комиттә бер батыр да җирдә егылып ятмагач.

Бармыни бездә гомумән чын кеше кадерен белү?
Без аны кайдан белик, мескен, үлеп аңлатмагач?

# *III. GLOSSARY*

# III GLOSSARY

The Tatar words are given in the following alphabetical order: а, б, в, г, д, е, ё, ж, з, и, й, к, л, м, н, о, п, р, с, т, у, ф, х, ц, ч, ш, щ, ъ, ы, ь, э, ю, я, ә, ө, ү, җ, ң, һ.

## ABBREVIATIONS

| | |
|---|---|
| adj. | adjective |
| adv. | adverb |
| Ar. | Arabic |
| caus. | causative |
| fem. | feminine |
| ger. | gerund |
| interj. | interjection |
| intr. | intransitive |
| ling. | linguistics |
| lit. | literally |
| masc. | masculine |
| n. | noun |
| onom. | onomatopoeic |
| pass. | passive |
| Pers. | Persian |
| pers. | person |
| pers. pron. | personal pronoun |
| pl. | plural |
| postp. | postposition |
| pr. n. | proper noun |

| | |
|---|---|
| R. | Russian |
| refl. | reflexive |
| sing. | singular |
| suff. | suffix |
| trans. | transitive |

Words marked with an asterisk occur only with concrete-relational (possessive) suffixes.

The pure-relational forms ("case forms") have the following names here:

| | |
|---|---|
| abl. | ablative ("from") |
| acc. | accusative (direct object) |
| dat. | dative ("to") |
| gen. | genitive ("of") |
| loc. | locative ("in, at") |

In the glossary only such meanings of words are given which occur in the texts.

A

абау interj. expressing fear or surprise

абзар shed for cattle

абзый see абый; uncle; title or form of address

абый elder brother

абыстай aunt; title or form of address, especially, the wife of a mullah

Австралия Australia

автор author

авыз mouth; oral

авыз иҗаты folklore

авыз тутыр- to eat one's fill; gorge

авыл village

авыл кешесе villager

авыл хуҗалыгы agriculture

авыллык quality or attribute of a village

авыр heavy; difficult; filled up

авыр- to fall ill; get sick

авырлык weight; load

авырт- to hurt; ache

авыру sick; weary; sickness; weariness

ага elder brother; form of address

агай uncle

агар- to pale; become pale; fade

агач tree

агула- to poison; contaminate; infect

агулан- pass. of агула-

агыз- caus. of ак-; to pour; tilt; shed tears

агызып җибәр- to pour out

Агыйдел the Agyidil River (Belaya, R.)

агыр see авыр

адаштыр- to deceive, lead astray

адым step; gait

адәм man, human being

адәмнәр pl. of адәм; people; human beings

аер- to separate; set apart; reject; deprive of (with abl.)

аерата particularly; especially

аеруча especially; exceptionally

аерыл- pass. of аер-

аерым separate; private

аз little; scarce; few

аз гына a little; somewhat

аза repast at a funeral; funeral banquet

азан call to prayer by a Muezzin

азат free; independent; freedom

азатлык freedom; emancipation

Азия Asia

азрак 1. in a while; after a brief pause

азрак 2. comparative of аз; less; a little; somewhat

азык food; provisions

ай 1. moon; month; in a month

ай 2. interj. oh! ah!

айгыр stallion

айн- to sober; come to one's senses

айнык sober; sensible

ак white

ак- to flow; become unravelled

аккош swan

аклы тарал- to become perplexed, confused

акрын slow; quiet; noiseless; slowly; quietly

акрынла- to hesitate; linger

актар- to rummage; turn over the pages

актык last; final

акча coin; money; finances

акыл reason; mind

акылга уртачарак dull-witted

акыллы clever; prudent; wise

акыр- to shout; roar

акырыш- reciprocal of акыр-

ал- to take; get; buy; start from; cut (hair); with the gerund in -а(-ый), -ә (-и) "to be able to"; with the gerund in -ып (-еп) aspect verb describing a rapid action

ала striped; skewbald

алай thus; so

алай да even so; yet; by the way

алай-болай this and that; for one reason or another

алай булгач thus; then; consequently

алайса if so; then

алар they

алафранка in the European fashion *olla franca R.-Ital.*

алга forward; forth

алга китү verbal noun of алга кит-; advancement

алд front; front side; with possessive suffixes: in front of

алда in front; before; vide алд

алда- to deceive

алдан before; beforehand; vide алд

алдан бел- to foreknow

алдан- pass. of алда-

алды* in front of; before; vide алд

алдына (up) to; in front of; before; vide алд

алдынгы before (adj.); leading; foremost; vide алд

алдында at; in front of; before; vide алд

алдындагы at; in front of; fore (adj.); vide алд

алдыннан before; from; vide алд

алка circle, halo; ear-ring

алкышла- to applaud

Алла Allah, God

алмаз diamond

алмау verbal noun of алма-, negative form of ал-

алмаштыр- to exchange; replace

алпан-тилпән staggering; reeling

алтмыш sixty

алты six

алтын gold

алтынлы gold-bearing; golden

алтынчы sixth

алу verbal noun of ал-

алын- pass. of ал-

алып ger. of ал-; from, starting from

алып бар- to take to; carry to; deliver

алып кайт- to bring (back)

алып кер- to bring (in)

алып кил- to bring

алып кит- to take away, carry away

алып ташла- to throw off, away

алып чык- to bring out; lead out

алыш verbal noun of ал-; fight; skirmish

алыш- to change; exchange [blows; fight]

амбар barn; granary

Америка America

амир commanding; commander, chief

амиранә in a commanding manner

ана mother

анда there

андагы there (adj.)

андый such

аннан abl. of ул 2

аннан соң then; later

аннары further; then

анчак only; barely; just

аны acc. of ул 2

анысы that, that one of his

аның gen. of ул 2

ап : ап-ак snow-white

апа aunt; elder sister; honorific title added to a woman's name

апрель April

аптыра- to be confused, at a loss; be in need

аптырау verbal noun of аптыра-

аптырат- caus. of аптыра-; to worry; annoy

ара space between; interval; middle; with possessive suffixes: between

аралашу ties, relations; acquaintance

арасына to the middle of; between; among; vide ара

арасында in the middle of; between; among; vide ара

арасыннан from the middle of; from; from among; vide ара

ара-тирә at intervals; in places; sometimes

арба cart; carriage

арка back n.

аркадан тел- to flog

аркасында at the back of; because of

аркан lasso; rope

аркылы by means of; through; with

армия army

арслан lion; brave man

арт back part; back

арт- to increase (intr.)

артта кал- to remain behind; lag

арттан behind; beyond

арттыр- caus. of арт-; to add; exceed

артыграк more

артык superfluous; in excess; more; more than; especial

артына to the back of; beyond; vide арт

артына әйлән- to turn around; vide арт

артыннан from the back of; beyond; after; vide арт

артыннан җит- to follow; trail; to overtake

артыннан җитмәкчи that follows; trailing; pursuit

артып ger. of арт-; in excess; more than

ару clean; in good health; well

археология archaeology

ары there; thither

ары- to become tired, exhausted

арыш rye

ас bottom; lower part

ас- to hang up; tag; suspend

асат easy; simple

аслый basic; fundamental; essential; real

асрау servant

аст lower part; downstairs

аста below; underneath

астан from below

Астрахань Astrakhan (city)

астрономия astronomy

асты-өскә кил- to turn over, upside down; topsy-turvy

астында below; under; vide аст

астыннан from below; from under; vide аст

асыл satin

асылда in essence; mainly; essentially

ат 1. name

ат 2. horse, steed

ат- to throw; shoot (at)

ата father

ата- to name

ата-ана parents

атал- pass. of ата-

аталар ancestors

атау island

атла- to step; walk

атлан- to mount

атлы with the name (of); named

атна week

ату verbal noun of ат-

атып чыгар- to shoot (through)

атып җибәр- to shoot, make a shot

ау- to fall; collapse

аулак remote; secluded

Африка Africa

ахмак fool; idiot

ахры it seems that; probably

ахрысы see ахры

ахыр end

ахыргы last; final

ахырда in the end, finally

ач hungry; emaciated

ач яңаклы thin; lean; gaunt

ач- to open; bare; open up; reveal

ачлык hunger

ачу anger; vexation

ачу кил- to become angry

ачу китер- to make angry; vex

ачу китереш verbal noun of ачу китер-

ачулан- to be agry, annoyed

ачулы with anger; angry; vexed, annoyed

ачуташ alum

ачы bitter; bitterness

ачык open; expressive; clearly; expressively

ачыктан-ачык openly

ачыл- pass. of ач-; to open (intr.); appear

ачын- to grieve; suffer

аш food; dinner; provisions

аш хуҗасы provider

аша- to eat

ашаган саен each time [he] ate

ашарлык suitable for food; edible; food, edibles

ашат- to feed

ашау verbal noun of аша- ; food

аш-су food and drink; diet

ашсыз without food

ашъяулык tablecloth

ашыгычлык haste; impatience

ашыр- to bring about; carry out

ашыручы bringing about; carrying out (adj.)

аяк foot; leg

аяклы with feet, legs; -footed

Hagia Sophia

Аясофия the Ayasofya Mosque in Istanbul

Аяте Кәримә the Noble Rhymes (Pers. genitive construction); a quotation from the Koran

аң reason; intellect

аңа dat. of ул 2

аңар dat. of ул 2

аңарда loc. of ул 2

аңгыра dim-witted; idiotic; simple

аңгыралык stupidity; foolishness

аңла- to understand

аңлаешсыз without understanding; incomprehensible

аңламак verbal noun of аңла- understanding

аңлат- caus. of анла-; to explain

аңлатма explanation

аңлатучы explaining; that explains

аңлау verbal noun of аңла-; notion

аңлаучы understanding; who understands

аңлы clever

аh interj. ah! oh!

аh-вah sighs, laments

-Б-

бабай grandfather; old man

багана pole

багышла- to dedicate; assign; devote

багышлан- pass. of багышла-

базар bazaar, market, market place

бай wealthy; rich; endowed; owner; wealthy man

бай бәтчә madame; wife of a rich man

байла- to tie; bind

байламаганлык verbal noun in -лык, negative form of байла-

байлык wealth; richness

байрак flag

байтак enough

бак- to look

бакча garden

бал honey

бала child

бала тап- to bear; give birth

бала-чага children; kin, family

балта axe

балык fish

балыкчы fisherman

бар 1. is; there is; there are; present

бар 2. all; wealth

бар- to go; last; aspect verb describing a continuous action

барабан drum (R.)

барика lightning, splendor

барикаи хакыйкать lightning (splendor) of truth (Pers. gen. construction)

барлык 1. all

барлык 2. existence

барлыкка китер- to bring into existence

бармак finger

бармыни is there?; see бар 1.

бару verbal noun of бар-

бары only

барын all; entire

барын да see барын

барып ger. of бар- to go

барып ал- to fetch

барып-барып while going; on the way

барып кер- to go in

барып кет- to go away

барып җит- to go as far as; reach

барысы all (of this; of these); vide бар 2.

барысында in its entirety; entirely; vide бар 2.

барча all

барчасы see барысы

бас- to step, tread; press down, press; print

бастыр- caus. of бас-; to print

басыл- pass. of бас-

басып кидер- caus. of басып кий-

басып кий- to put on tightly, pull over one's ears (headwear)

бастыр- caus. of бас-

басыл- pass. of бас-; to be overcome; end

бат- to sink; set (of sun)

бату verbal noun of бат-

батыр hero; athlete

батырларча heroically

бау string, cord, lace

баш head; beginning; source; top

башбаштак wilful; self-willed

башка other, different, unusual, special; other than, apart from, but for (postp. with abl.)

башкачарак in a different manner

башка җит- to ruin; destroy

башкорт Bashkir (n., adj.)

башла- to begin

башлан- to begin (intr.)

башлангыч initial; basic; primary

башлау verbal noun of башла-

башта vide баш and баштан

баштан at first; first; vide баш

баягы former; above mentioned

без 1. pers. pron. we

без 2. awl

безнең our; see без

бел- to know; learn; believe

белдер- to make known

белдерт- caus. of белдер-

белем knowledge; skill

белем ал- to learn; study; acquire knowledge

белен- pass. of бел-; to become clear

белмичә unwittingly

белмәк verbal noun of бел-; knowledge

белән with; and; by; through; by means of; as soon as; although

белән бергә together with

белү verbal noun of бел-; knowledge

белүче knowing; he who knows

бени sons (Ar.)

бер one; a; some; once

бер-бер one by one; separately

бер-берсе each other; one another

бер генә but once; at one stroke

бер дә at all; not at all (in negative constructions)

бер заман at one time; once

бер-ике one or two

бер кат one time; once

бер кеше someone; a person

бер көнне one day; on a day

бер такым some; any

бер җирдә somewhere

беравык for a while; a while

бераз a little; somewhat

бервакыт see бер заман

бервакытны see бервакыт

бервакытта see бервакыт

бергә together

бергәләп together; in common

берданбер sole; only

берегез one of you

беренче first

беренче нәүбәттә in the first instance; first of all

беренчедән firstly; first

беркадәр a little; somewhat

беркем дә no-one (in negative constructions)

ныгыт-

беркет- to strengthen; affirm

беркөн one of these days, some days ago

беркөнне see бер көнне

берлектә together

берлә with; by

берлән see берлә

берничә several; a few

берничәнче one of several (in enumeration)

бернәрсә something; anything

берсе one of these; one

бертөрле of one kind; incessant; any (in negative constructions)

берәм-берәм one by one; separately

берәр some; any

берәү someone; somebody

берәү дә no-one (in negative constructions)

бет- to end; perish; go; aspect verb describing a completed action

бетер- to finish; destroy; abolish; ruin; spend; aspect verb describing a completed action

бетмәс endless

бетү verbal noun of бет-

биграк in excess; more; especially; rather than

бик very; very much; extreme; excessive; excessively

Биктимер pr. n.

бил waist

бил бәйлә- to rely on (with acc.)

билге sign; mark

билгеле known; some; certain; of course

билгелә- to make a mark; determine, specify, denote

билгеләде past tense of the previous

билә- to wrap; swaddle

биләү verbal noun of билә-

биография biography

бир- to give; aspect verb describing an action directed away from the speaker

бире hither; here

биредә here

бирел- pass. of бир-

бирелгәнлек noun in -лек from participle in -гән of бирел-; a being given

бирелү verbal noun of бирел-

бирешерлек noun in -лек of бирешер: surrendering; yielding

бирештер- caus. of биреш-

бирле since; from the time of (postp. with abl.)

бирү verbal noun of бир-

бит 1. face; page

бит 2. yet; no doubt; however (R.)

бит әле however; but

битлек mask; net

биттабгы naturally, of course

битәр in excess; more than (with abl.)

бичара unfortunate; wretched

биш five

биш йөз five hundred

бишек cradle; cot

бишенче fifth

бишенчегә for the fifth time

бишмәт quilted jacket

бия mare

бияләй mittens

богдай wheat

боер- to command; order

боз ice; hail; ice particle

боз- to spoil; upset; alter

бозу verbal noun of боз-

бозык spoilt; ruined

бозыклык depravity

бозыл- pass. of боз-

болай thus; so; just

болар these; they

Болгар Bolgar, capital city of the ancient Bolgar kingdom on the Volga River

болгат- to mix; stir

болыт cloud

